***Расули Габдррахман (1881—1950) — муфтий ЦДУМ и ДУМЕС, шейх. Он родился в ауле Ак-хужа Златоустовского уезда Уфимской губернии. Получив образование в медресе своего отца З. Расули «Расулия», в 1899 г. совершил хадж, стал шейхом ордена «Накшбандийа», после чего обучался в университете «ал-Азхар» в Каире. С 1903 г. он стал ректором «Расулии», где преподавал арабский язык и историю ислама. На III Всероссийском мусульманском съезде***



www.darul-kutub.com

***1906 г. он вошел в состав религиозной комиссии съезда, руководимой г. Баруди. После смерти отца в 1917 г. Расули возглавил его приход при 5-й мечети Троицка. С 1923 г. он стал мухтасибом Уральской области. На съездах мусульманского духовенства в 1923 г. и в 1926 г. при ЦДУМ Расули был избран членом Голямалар Шурасы. В 1936 г. в результате борьбы, развернувшейся после смерти муфтия Р. Фахретдина и последовавших арестов членов ЦДУМ, Расули стал муфтием. В мае 1942 г. муфтию удалось провести съезд духовенства при ЦДУМ, где было принято обращение ко всем мусульманам СССР с призывом защищать Родину. г. Расули выдал 917 свидетельств на право совершения обрядов, не связывая их получение с открытием приходов. В 1945-1946 гг. он пытался организовать при ЦДУМ курсы по подготовке имамов, в чем ему было отказано. Муфтий ежегодно публиковал мусульманские лунные календари, в 1945 г. издал свое религиозное пособие «Ислам дине» (Религия ислама). В 1945 г. и 1947 г. он совершил хадж. В 1947 г. биография Расули была включена в издание американского справочника «Who Is Who In Religion» («Кто есть кто в мире религии»). В 1948 г. Р. провел первый с 1926 г. съезд мусульманского духовенства, где ЦДУМ было трансформировано в ДУМЕС.***

В поражении нацизма верующие всего мира видели победу Бога против Дьявола. Не случайно ветхозаветная фраза «Не в силе Бог, а в правде», приписанная святому защитнику православия Александру Невскому, облетела все фронты. Фашисты объявили «неарийские» народы «унтерменш» — недолюдьми. Эта старая теория Гегеля, делившая народы и государства на полноценные и неполноценные (материал для немецкой расы), была воспринята как нацистами, так и частью большевиков. Поэтому татары-мусульмане в тылу и на фронте, в фашистском плену и эмиграции были едины в



www.darul-kutub.com

ожидании крушения режима, отринувшего все нормы Божественного права и справедливости.

С этого времени в СССР официально отказались от политики уничтожения религии, но мусульмане ЦДУМ не дождались принципиальных изменений. С созданием в 1943 г. ДУМ на Северном Кавказе, в Закавказье и Средней Азии ЦДУМ окончательно утратило свои центральные функции. К Среднеазиатскому Духовному управлению мусульман не только перешла территория Казахстана, но в Бухаре было открыто единственное в СССР медресе «Мир-Араб» (1945) и начал издаваться единственный журнал «Мусульмане Советского Востока» (1947), своеобразный преемник «Ислам маджалласы». Ташкент как основной центр советских мусульман сменил Уфу. Поэтому в 1948 г. на съезде мусульманского духовенства ЦДУМ было преобразовано в Духовное управление мусульман Европейской России и Сибири (ДУМЕС) и был принят новый Устав, по которому из его ведения были изъяты такие полномочия, как создание медресе и мектебов, организация курсов для подготовки служителей культа, образование мухтасибатов, ведение метрических книг. ЦДУМ сохранило чисто богословские функции, контроль за назначением духовенства, учет мечетей и молитвенных домов. Власти привели законодательство в соответствие с практикой и начали ориентироваться на физическое вымирание духовенства и активных верующих.

***Айдар ХАБУТДИНОВ,***
***доктор исторических наук***



www.darul-kutub.com

# ДӘҮЛӘТНЕҢ ДИНИ СӘЯСӘТЕНДӘ — ЛИБЕРАЛЬЛӘШТЕРҮ

Бөек Ватан сугышыннан соң, илебездәге мөселманнар тормышы дәүләттәге дини сәясәтнең чагыштырмача либеральләшү фонында бара.

Утызынчы елларда, мәчетләрне тоталь ябулар һәм профессиональ дин эшлеклеләренә карата алып барылган репрессияләр нәтиҗәсендә, сугыш азагы чорына гыйбадәт йортлары саны нык кимегән, мәсәлән, Башкортстан территориясендә генә дә, 1927 елны булган ике мең ярым мәчеттән 12 рәсми теркәлгән мәчет торып калган. Республикадагы барлык мөселман халкының дини тормышы шул унике мәчеткә генә кайтып калмаган, әлбәттә. Ул әкренләп өйләргә, гаиләләргә күчкән, ә диндарлык исә, чит күзләрдән ныклап яшерелгән, нигездә, тормыш-көнкүреш даирәсенә күчкән.

Мөселманнарның дини тормышлары һәм көн саен исламга мөрәҗәгать итүләре — сизелмичә үткән. Авылларда эшли торган мәчетләрдә дини йолалар башкарылган, аларга, җомга көннәрендә, 5-10 кеше килгән. Өйләрдә башкарылган бар йолаларны, тормыш-көнкүрештәге динилекнең исәбен, хәтта, барысын да күреп торучы СРК вәкиле дә исәпләп, күзәтеп бара алмаган. Шуңа да карамастан, аның хисаплары буенча, ул вакытларда да авылларда балаларны сөннәткә утыртучы «сөннәтче бабайлар» йөргән.

Дини тормышның дәвам итүе дини бәйрәмнәрне билгеләп үткән вакытта аеруча күренгән. Мөселманнар ел саен ураза, корбан һәм мәүлид бәйрәмнәрен билгеләп үткән. Бәйрәм көннәрендә эшчәнлекләрен алып баручы мәчетләр



www.darul-kutub.com

каршында, шул ук вакытта эшчәнлекләрен алып бармачылары каршында да зур халык төркемнәре җыела торган булган. Сугыш беткәннән соң үткәрелгән беренче мөселман бәйрәмен — ураза гаетен билгеләп үтәр өчен, ә ул 1945 елның 7 сентябренә туры килгән, Уфаның Җәмигъ мәчетенә генә дә 3 мең кеше җыелган. Ә шул ук елның корбан бәйрәмен үткәргән вакытта инде (1945 елның 15 ноябре) ун мең кеше катнашкан[1]. 50нче еллар башына кадәр бәйрәм көннәрендә мәчетләргә килүчеләрнең саны чагыштырмача бер тирәдәрәк булган. Мәчеткә килүчеләрнең 10-30 проценты хатын-кызлар, алардан тыш, үзәк мәчетләрдә, ата-аналары белән килгән 30-50 бала да дини йолаларны башкаруда катнашкан.

Ураза бәйрәме белән төгәлләнә торган рамазан аенда, һәр төн саен тәравих намазы укыганнар, җомга көннәрендә үзәк мәчетләргә җомга намазына 200-250 кеше килгән, ә өлкән яшьтәгеләр ураза тотканнар (150шәр кеше). Бу вакытта хакимият органнары ураза тоту, дини бәйрәмнәр үткәрү эшкә йөрүдә, җәмәгать һәм хезмәт тәртибендә чагылыш алмавын зур таләпчәнлек белән күзәтеп торган.

Ураза тотучы мөселманнарга көндез эшләргә туры килгән. Күпләре ураза тотуларын яшергән. «Ураза тотучылар әңгәмәләр үткәреп ачыкланды, тик барысы да ураза тотуларын танып бармыйлар. Ураза тотуларын күрсәтмәскәрәк тырышалар, чөнки бу аларда шәригать буенча тыелган гамәл — мактану булып исәпләнә»[2], — дип яза СРК вәкиле.

Корбан бәйрәме вакытында, ислам кагыйдәләренә туры китереп, корбан итеп сарыклар чалганнар, аның итен пешереп бәйрәм сыйлары оештырганнар, итнең бер өлешен туганнарына, күршеләренә таратканнар. 1947 елны Уфада

1. Информацион Отчетлар. 1945.
2. Информацион Отчетлар. 1948.



www.darul-kutub.com

корбанга 50 сарык чалынган, ун сарык тиресе муллаларга хәер итеп бирелгән. Ә бөтен Башкортстан буенча, барысы 3000 сарык чалынып, алар тиресенең 30 процентына кадәр дәүләт әзерләү оешмаларына сатып тапшырылган.

Корбан бәйрәме вакытында мөселманнар өйләрендә башка мөселманнарны һәм мулла чакырып корбан ашлары үткәргәннәр. Бәйрәм сыйлары үткәрүче мөселманнар шулкадәр күп булган, алар хәтта муллаларны чакырыр өчен чиратка язылган. Ә муллаларга исә, үз көннәрен сәгатьләп планлаштырырга туры килгән. Мөселманнар өчен Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көненә багышланган мәүлид бәйрәме изге көн булып исәпләнә. Өч көн бара торган бу бәйрәм вакытындагы төнге вәгазьләрдә Пәйгамбәр (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын!) турында сөйләнә. Көндез күп урыннарда мәүлид ашы үткәрәләр. «Мөселман бәйрәмнәре көннәрендә халык мәчетләргә шатланып, күтәренке күңел белән килә» дип, даими рәвештә билгеләп бара вәкил. Мәчетләргә мөселманнар гына түгел, ә кызыксынып, шәһәр халкы да килә. Алар арасында татарлар да, башкортлар да, башка милләт вәкилләре дә була. Мәчет ишек алдында теләнчеләр күп җыела, алар өчен бу көннәр аеруча зур уңыш белән тәгәлләнә. Өлкән яшьтәгеләр әлеге йолаларда катнашучыларның 70 процентын тәшкил иткән, ә яшьләр — биш процентын.

Дини йолаларны башкарырга килүчеләр, гадәттә, ун-унбишәр кешелек төркемнәргә җыелып, юлда вакытта ук тәкбир әйтеп мәчеткә бара торган булган, чатларда, тыкрыкларда туктап, кычкырып Аллаһыны олылаганнар.

Мөселманнарның хәер-сәдакалары мәчетләрнең генә түгел, ә Диния нәзарәте табышларының да төп мәддәсе булган. Гадәти көннәрдә даими керемнәр зур булмаган. Аның урынына, дини бәйрәмнәрдә мөселманнардан акча җыю



www.darul-kutub.com

үткәрелгән һәм Диния нәзарәтенең казнасы нык кына тулыланган. Җыелган бар хәйрия акчалары да Диния нәзарәтен, мәхәлләләрдәге мәчетләрне тотарга, зиратларны төзекләндерергә, хаҗга баруны оештырырга, ятимнәргә ярдәм итәргә һәм башка хәйрия максатларына тотылган.

Әйтеп үтик, сүз рәсми рәвештә теркәлгән мәхәлләләр, дини җәмгыятьләр турында бара. Ачык күренеп тора, андый сандагы рәсми теркәлгән дини җәмгыятьләр генә бар мөселманнарның да дини хаҗәтләрен канәгатьләндерә алмаган. Нәтиҗәдә, мөселманнарның күп өлеше «рәсми теркәлмәгән» дип аталучы дини җәмгыятьләргә (20 һәм аннан күбрәк) һәм дини төркемнәргә (5-10 кеше) берләшергә мәҗбүр булган. Күп кенә дини җәмгыятьләрнең эшчәнлеге 1940 елга кадәр үк, ә кайберләре исә сугыш башланыр алдыннан гына тыелган булган. Шулай да мөселманнар үзләренең ул җәмгыятьләрен канунсыз дип исәпләмәгән, аеруча 1946 елның 28 гыйнвар карарыннан соң. Мәчетләрне һәм дини җәмгыятьләрне торгызу буенча гариза бирү, алар фикеренчә, дини эшчәнлекне дәвам итәргә җитәрлек нигез булып торган.

Теркәлмәгән дини җәмгыятьләрнең, кагыйдә буларак, үз дин әһелләре булган. Гадәттә, элеккеге муллалар. Һәрхәлдә, аларны шундый сыйфатта таный торган булганнар. Төркемнәрне очраклы кешеләр җитәкләгән, алар шул ук вакытта дини хезмәтләр, йолаларны башкару функцияләрен дә үз өсләренә алган. Алар, гадәттә, Коръән, догаларны, дини кагыйдәләрне яхшы белгән өлкән яшьтәге кешеләр булган.

Андый төркем һәм җәмгыятьләрнең булуы җирле хакимият органнарын, СРК вәкилен зур куркуга төшергән. Соңгысы, теркәлү алмаган җәмгыятьләрнең эшчәнлеге турында үзенә ни дә булса мәгълүм булган саен, шунда ук куркынычсызлык органнарына җиткергән: «Куркынычсызлык



www.darul-kutub.com

Нәзарәтенә. Сезнең игътибарыгызга шуны җиткерәм, кайбер район һәм шәһәрләрдә, элеккеге мулла һәм башка дин эшлеклеләре җитәкчелегендә төрле мөселман төркемнәре, дини йолалар башкару өчен рәсми рөхсәт алмыйча, гыйбадәт кылалар ... Алда санап үтелгән барлык бу төркемнәр дә, якында эшләп килүче гыйбадәт йортларына кушылырга төрлечә каршы торалар. Элеккеге дин әһелләре, салымнар түләүдән читләшер өчен төркемнәрен легальләштермиләр ...» (Кәримов)[1].

Рәсми теркәлү үткән җәмгыять мөселманнары дини йолаларны, күп халык җыелган мәчетләрдә башкарганнар, дини йолалар муллалар җитәкчелегендә үткәрелгән. Эшләп торган мәчетләрнең саны аз булу сәбәпле, мөселманнарның күп өлешенә догалар укуны, дини йолаларны өйләрендә башкарырга туры килгән. Җомга көннәрендә, дини бәйрәмнәр вакытында, алар берәр мөселманның өендә, яки ябылган, беркем тарафыннан да файдаланылмый торган иске мәчетләрдә, яисә бөтенләй ачык күк астында, зиратларда җыелып җәмәгать намазларын укыганнар. Андый җәмәгать намазларында катнашучылар саны, рәсми теркәлү алган мәчетләрдә гыйбадәт кылучылар санынннан күпкә кимрәк булган, ул 20-100 кеше арасында тирбәлгән.

Авылларда профессиональ дин әһелләре җитмәү үзен нык сиздергән. Шул ук вакытта, күп кенә элеккеге муллалар, хакимият органнары эзәрлекләүләреннән һәм салымнар салудан шикләнеп, дини йолаларны башкарудан баш тартканнар. Элеккеге дин әһелләренең дини йолалар башкаруда катнашулары турында үз хисапларында билгеләп үтеп, СРК вәкиле: «Алда әйтеп кителгән сукбай муллаларның гамәлләре турында, минем тарафтан җирле органнарга җиткерелде. Аларның исемлеген мин, аларга табыш

1. Информацион Отчетлар. 1951.



www.darul-kutub.com

салымы салу предметы буенча тикшерергә, финанс органнарына бирәм»[1], — дип яза.

Мөселманнарга дини йолаларын башкарыр өчен, еш кына, күрше авылларда рәсми теркәлү алган гыйбадәт йортлары булуына сылтап, үз авылларында рөхсәт бирмәгәннәр. Андый «күршелек» ун яки аннан да күбрәк чакрым ераклыкта да булган. Келәш авылы мөселманнары дүрт чакрымдагы Каран-Елга авылына йөрергә теләмиләр, ә тәтешлеләр — 15 чакрымдагы Сәйтәк авылына, Тимкәнекеләр — шулай ук Сәйтәккә, шулай ук 15 чакрымга, дип зарлана вәкил[2].

Мөселманнарның дини тормышында изге Мәккәгә хаҗ кылуны яңадан торгызу зур вакыйга була. 1945 елның 26 октябрендә мөфти Рәсүлев мөселманнарга: «Хөкүмәт, мөфти җитәкчелегендәге 17 кешелек мөселман төркеме төзеп, 1945 елның декабрендә хаҗ кылырга барырга рөхсәт бирде», — дип игълан итә. Хаҗ кылып кайтканнан соң мөфти зәм-зәм чишмәсеннән алынган изге суны мөселманнарга таратуны оештыра.

1947 елны бар дини нәзарәтләрдән дә (Үзәк, Урта Азия, Төньяк Кавказ, Кавказ арты) 40 кеше хаҗ кылырга бара. Хаҗ кылырга баруга һәм аны оештырыр өчен рөхсәт алуга ирешү бик кыен була.

1946 елны СРК «... Ирандагы авыр метеорологик шартлар, автомобиль һәм тимер юллар булмавы һәм диңгез юлының ышанычсыз булуы аркасында»[3] рөхсәт бирми. Ә 1948 елны хаҗга бару «гарәп илләре арасында сәяси мөнәсәбәтләрнең катлаулануы һәм Иранда ваба авыруы таралуы»[4] аркасында булмый кала. Хаҗ кылырга баручылар саны нык чикләнә,

---

1. Информацион отчетлар. 1946.
2. ЦГИА РБ. Ф. 4732. Оп. 1. Д. 2. Л. 39.
3. ЦГИА РБ. Ф. 4732. Оп. 1. Д. 2. Л. 4.
4. ЦГИА РБ. Ф. 4732. Оп. 1. Д. 2. Л. 5-9



www.darul-kutub.com

анда баручылар кырыс сайлап алу һәм куркынычсызлык органнарының тикшерүләрен үтәләр, һәм аннан тыш, күпләренең хаҗ кылырга барыр өчен җитәрлек акчалары да булмый.

Илнең мөселман төбәкләрендә шактый сандагы изге урыннар була. Мөселманнар ул изге урыннарга, зиярәт кылырга дип, дини бәйрәмнәрдә дә һәм мондый көннәрдә дә килә торган була.

Андый зиярәт кылулар Ватан сугышы елларында бик популяр була, ул вакытта мөселманнар догаларда юаныч алуга аеруча мохтаҗлык кичерә.

Мөселманнарның бу зиярәт кылулардагы активлыгы аларда дини традицияләрнең нык булуы хакында да сөйли. Хакимият органнары исә, бу изге урыннар дин әһелләре һәм оешмаларына күп табышлар бирә һәм дини карашларның ныгуына китерә дип исәпләгән.

1946 елдан башлап СРК бу изге урыннарны зиярәт кылу турында, аларны бетерү максатыннан, белешмәләр җыя башлый. Зиярәт кылулар зарарлы хорафатлар дип игълан ителә. Рәсми дини җитәкчелек тә бу зиярәт кылуларга каршы канәгатьсезлек белдерә, андый табынулар, борынгы вакыттан ук мәҗүси традицияләр калдыгы булып исәпләнгән. 60нчы елларда дин галимнәре, мөселманнарга тиешле мөрәҗәгать кабул итеп, хакимиятнең мондый изге урыннарга табынуны бетерүгә турындагы күрсәтмәсен хуплыйлар.

Россиянең ислам белгечләре бу фактны дин әһелләренең исламга «тәрәккыять бирергә омтылуы» дип карый. Белгечләр фикеренчә, мондый тәрәккыять мөселман культының «эволюциясен»[1] чагылдырган. Инкыйлабка кадәр дә шәһадәтнамә буенча тәгаенләнгән муллалар бу җирле «изге

1. Калимуллин Б. г. Архитектурные памятники Башкирии. Вып. III. — Уфа, 1958, 345 с.



www.darul-kutub.com

урыннарга» табынуны (анда потларга табыну күреп) шулай ук хуплап карамаган.

Сугыштан соңгы чорларда илдәге исламның хәлен тикшергән вакытта бар дин әһелләренең дә, бер искәрмәсез дип әйтерлек, шул ук вакытта рәсми теркәлү алмаган мәчет муллаларын да кертеп, өлкән яшьтәге кешеләр булганлыгын күрми калу мөмкин түгел. Дини белемнәр, имам-хатыйб исемнәре аларга XX гасыр башында ук, Беренче Бөтендөнья сугышына кадәр үк бирелгән булган.

Сугыштан соң инкыйлабка кадәр эшләп килгән күпсанлы мәдрәсәләрнең берсе дә калмаган, ябылып беткән. Илдә мөселман дин әһелләре әзерләүче бердәнбер уку йорты Бохарадагы Мир-Араб мәдрәсәсе була. Ләкин анда Татарстан өчен беркем дә укымаган.

Мондый вазгыять мөселманнарны, МҮДНне, мөфти Габдрахман Рәсүлевнең үзен дә борчымый калмаган. Алар СРКга, имамнар әзерләү өчен, 30 кешелек кыска сроклы дини курслар булса да ачарга рөхсәт сорап берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән. Укыту программасы әзерләнгән, ул программага Коръәнне, хәдисләрне, дин кагыйдәләрен, ислам этикасын, СССР Конституциясен укыту кертелгән.

1946 елны Рәсүлев СССРның Министрлар Советы каршындагы СРКка җәйге курслар булса да ачуны рөхсәт итүне сорап гариза юллый. Әмма курслар ачылмый кала, чөнки « ... бу курсның тыңлаучылары уку вакытында үзләрен тәэмин итә алмыйлар»[1] икән.

1948 елны кабул ителгән МҮДНнең уставы киләчәктә нинди дә булса дини уку йортларын булдыру мөмкинлеген бөтенләй юкка чыгара. 30нчы еллар репрессияләрен кичергән өлкән яшьтәге профессиональ дини кадрлар елдан ел кими, аларны алмаштырырлык бер кеше дә булмый.

1. Аширов Н. Эволюция ислама в СССР. М.,1972. С. 57



www.darul-kutub.com

Мөселманнарның күп өлешенең дини тормышы, күрүебезчә, йә тыелган, йә хакимиятнең бар урыннарга да үтеп керә торган контроле астында булган. Тик, шуңа да карамастан, ул яшәвен дәвам иттергән. Ул гына да түгел, сугышның соңгы елларында импульс алып, Башкортстандагы дини тормыш инерция буенча үсешен дәвам иткән.

Бу очракта, тикшерү алып барган чорда, динилекнең саклануы һәм алга таба үсүенә китергән факторларны күрсәтеп китәргә кирәк.

1. 30нчы еллардагы репрессияләр белән ил халкын бик нык кыскан хакимияттән курку хисе чамасыз газаплар һәм халыкка зур корбаннар китергән Бөек Ватан сугышы чорында юкка чыккан. Илне тышкы дошманнардан азат итү халыкның рухи хөрлек алуы белән бергә барган.

2. 1943-1948 елларда хөкүмәтнең дини сәясәт өлкәсендә азмы-күпме либеральләшүе булган, мөселманнарга һәм дин әһелләренә өлешчә ташламалар эшләнгән. Халык 1946 елның 26 гыйнварендәге карарны хакимиятнең дини сәясәт өлкәсендә җибәргән хата һәм ялгышларын тануына дәлил итеп кабул иткән. Һәм бу ялгышларны киң күңел белән гафу итәргә әзер дә булган. Мөселманнарда дини активлык күтәрелә башлаган, ул гыйбадәт йортларын, дини җәмгыятьләрне яңадан торгызуда чагылыш тапкан.

3. Динилекне саклау һәм кире торгызуда мөһим фактор: кадрларның — инкыйлабка кадәр үк күпсанлы авыл мәктәп һәм мәдрәсәләрендә (шул чордагы урта һәм югары дини уку йортларында) тулыкыйммәтле белем алган кадрларның сакланып калуы. Аларның күбесе тоткынлыкта булып кайтса да, куркуларын җиңеп, дини эшчәнлекләрен дәвам итәргә әзер булган.

4. Ниһаять, дини кануннарны, кагыйдәләрне, йолаларны белү халыкның үзендә дә сакланып калган. Ислам, тормыш рәвеше буларак, ике буын вәкилләреннән торган күп гаиләләрнең тормыш-көнкүрешендә сакланган.



www.darul-kutub.com

Соңгы ике фактор, безнең карашка, аеруча әһәмиятле. Нәкъ менә белемле дин әһелләре буынының, шул ук вакытта гаиләдә традицион дини белем алган кешеләрнең табигый юкка чыгуы белән дини тормышның әкренләп сүрелүе күзәтелә дә. Ә бу сүрелү, котылгысыз рәвештә, 70нче елларның дини кризисына, шул елларның рухи һәм иманлылыкны югалту кризисына китергән.

***Марат МӘРДАНШИН,***
***тарих фәннәре кандидаты,***
***Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые***



www.darul-kutub.com

# НӘРСӘ УЛ ҖИҺАД?

Соңгы вакытта, ислам дине турында сүз чыкты исә, еш кына «җиһад» сүзе калкып чыга. Мәгълүмат чараларында да күпләрне әлеге сүз белән өркетәләр, шуңа да «Ислам динендә җиһад нәрсәне аңлата соң?» дигән сорау белән мөрәҗәгать итүчеләрнең шактый булуы бер дә гаҗәп түгел. «Җиһад» гарәпчәдән турыдан-туры тәрҗемә иткәндә «тырышу», «дәрт» дигән мәгънәне аңлата. Бу — изге гамәлләр өчен, рәхәтлекләр хакына тырышу. Җиһад ике: эчке һәм тышкы төрдә була. Эчке җиһад дигәндә үз җитешсезлекләреңне төзәтү, үз кимчелекләрең, безне эчтән кимерүче иләс-миләслек белән көрәш күзаллана. Бу нәкъ менә бөек җиһад төшенчәсе хакына уйланылган төп җиһад инде.

Сугышларның берсеннән соң пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с) үз сәхабәләренә: «Әйдәгез, хәзер кече җиһадтан бөек җиһадка күчик», — дип мөрәҗәгать иткән. Ә алар исә аптыраштa калып: «Ничек инде алай? Әле генә без яулаган җиңүдән дә олырак көрәш, бөек җиһад бармыни?!» — дип сорап куйганнар һәм шундый җавап ишеткәннәр: «Әйе, бар. Бу — үзеңне-үзең җиңү җиһады. Үзеңдәге җитешсезлекләрне, кимчелекләрне җиңү. Бөек җиһад шушы». Үзеңнән башкага юнәлдерелгән җиһад, ягъни изгелек өчен көрәш, тырышу берничә төргә бүленә: бу — сүз белән җиһад, бу — шәхси үрнәгең белән җиһад, бу — югары идеаллар хакына кулга корал алып җиһад кылу. Әгәр дә кеше дөрес нәрсәләр турында сөйләсә яки башкаларга үз тормышларын үзгәртергә булышса, йә инде үзенең шәхси үрнәге белән бүтән кешеләргә бәхеткә илтүче юлны күрсәтсә, бу инде нәкъ без көткән, ниндидер яктылык, яхшылык алып килүче җиһад була. Әмма, шулай да, безне барыбер кулга корал тотып яуланган җиһад турындагы сорау борчый.



www.darul-kutub.com

Тышкы кече җиһад һәрчак эчке, бөек җиһадның дәвамы булып тора. Шуңа да кеше дөньядагы явызлык белән көрәшкәндә һәрвакыт үз уй-теләкләренең изге булуына игътибар итәргә, үз гамәлләрен һәрчак бөек идеаллар белән чагыштырырга тиеш. Бу җәһәттән, ислам диненең бөек каһарманы Гали (р.г) турында бик тә мәгълүм бер вакыйга бар. Сугышларның берсендә ул дошманын җиргә егып сала, башы өстендә кылычын күтәрә, әмма тегесе соңгы мизгелдә аның битенә төкерә. Һәм Гали хәзрәт дошманын җәзалыйсы урынга, көтмәгәндә һәм аның гаҗәпләнүенә каршы, кылычын түбән төшерә һәм үз дошманын иреккә җибәрә. Тегесе гаҗәпләнеп: «Ни өчен син мине үтерми калдырдың? Без дошманнар бит, югыйсә», — дип сорый. Моңа каршы Гали хәзрәт: «Син миңа төкергәндә, мин үземдә көчле ачу тойдым. Әгәр дә мин шул чакта үтергән булсам, үз ачуымны гына алыр идем, ә үзем инанган бөек идеаллар өчен түгел», — дип җавап кайтара. Шуңа да тышкы җиһадны эчке җиһад белән чагыштыру кешеләр алып барган көрәш, шул исәптән кулга корал тотып алып барылганы өчен дә аерылгысыз шарт булып тора. Бөек Ватан сугышы елларында мөселманнар тарафыннан игълан ителгән җиһад та моңа мисал. Бу — ниндидер бер киная генә түгел. Мөселманнарның Диния нәзарәте рәисе, мөфти Габдрахман хәзрәт Рәсүлевнең СССР мөселманнарын фашистик Германия нацистларына каршы җиһадта катнашырга чакырып мөрәҗәгать белән чыгуын дәлилләгән тарихи документлар бар. Әлеге мөрәҗәгать күп кенә мөселман халыкларының туган телләренә тәрҗемә ителгән һәм мөселманнар күпләп яшәгән төбәкләргә таратылган. Ул заманында мәчетләрдә укылган, «Труд» газетасында басылып чыккан.

Шунысын да искәртү мөһим, Бөек Ватан сугышы елларында мөселманнар алып барган җиһад, аларның яу кырында ятып калуы Сталин хакына, Алласыз тоталитар режим хакына түгел, ә бөек идеаллар өчен, илне саклау һәм аның бәйсезле-



www.darul-kutub.com

ге хакына. Мөселманнар гомер бакый яшәгән җирләре өчен көрәшкән. Әлеге сугыш Аллаһы Тәгалә хакына булды. Шуңа да Россия мөселманнары күз алдында Бөек Ватан сугышы җиһадында һәлак булган кешеләр — шәһидләр, ягъни алар үз диннәре, иманнары өчен газап чиккән. Алар истәлегенә Мәскәүнең Поклон тавында православие храмы һәм яһүд динендәгеләр часовнясы белән янәшә Бөек Ватан сугышы елларында туган илебезне һәм азатлыгыбызны яклап һәлак булган мөселманнар өчен салынган шәһидләр мәчете, ягъни газап чиккәннәр мәчете төзелә.

Кораллы җиһад та һәрвакыт югары идеаллар белән чагыштырылырга тиеш. Ул беркайчан да диндар кешеләрнең дини омтылышларын мәкерле максатларда файдаланучы бозык сәясәтнең аерылгысыз өлеше булырга тиеш түгел. Шуңа күрә, әгәр дә җиһад югары идеаллар хакына түгел, ә пычрак уй-теләкләрне күздә тота икән, Аллаһ юлындагы изге эштән гөнаһлы эшкә әверелә. Шундый ук хәлне без башка дини күрсәтмәләрдә дә күзәтәбез. Мәсәлән, канун саналырдай намазны алыйк. Әгәр дә ул тиешле шартлары үтәлмичә укылса, (мәсәлән, төш вакытында яки кояш чыкканда яисә кояш баеганда укылса), бу вакытта мәҗбүри гыйбадәттән күңелгә ятмаган, кирәксез нәрсәгә әйләнә. Әгәр инде кеше гыйбадәт вакытында явыз ният белән башкаларга зыян сала, мәсәлән, берәрсенең намазлыгын урлый яки тагын нindидер хилафлык кыла икән, бу очракта намаз гөнаһка әверелә. Җиһад белән дә шундый ук хәл. Бер гаепсез кешеләрне үтерүгә яки шәһид билбаулары бәйләп үзләрен тыныч халык арасында шартлатып, аларның гомерен өзүгә китергән гамәлдән һәммәбез зыян күрә. Шуңа да ул берничек тә җиһад дип санала алмый.

Кызганыч, хәзер мөселманнарның мөмкинлекләре чикләнгән. Мәсәлән, аларга карьера ясау торган саен кыенлаша, үзләренә каршы юнәлтелгән җәмгыятьтә яшәве дә авырла-



www.darul-kutub.com

ша бара. Әлеге тискәре карашның тамыры шунда: кайбер кешеләр сәяси уеннарда уйный һәм җиһадның югары рухи төшенчәсен үзләре кылган гөнаһлы гамәлләр белән чикли. Мондый кыланышлар берничек тә җиһад була алмый, алар гөнаһлы, Аллаһы Тәгаләнең мондый гамәлләргә ачуы көчле. Бүгенге көндә бу турыда белеп тору аеруча мөһим.

***Рөстәм БАТЫРОВ,***
***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте***
***рәисенең беренче урынбасары***



www.darul-kutub.com

# БАБАЛАРЫБЫЗ ҮРНӘГЕН ОНЫТМЫЙК

Бөек Җиңүне бәйрәм итү көне, ягъни 9 Май алдыннан безгә тарихның асылы һәм ул сугышта өстен чыккан халыкның язмышы турында барыбызга да уйланырга кирәктер.

Билгеле булганча, тарихны җиңүчеләр яза. Әмма XX гасырның 40 нчы елларына карата бу фикерне куллану гадел булмас, чөнки сугышта җиңеп чыгучы як, бихисап кешесе һәлак булганга күрә, аеруча кыен хәлдә калды. Мондый сугышлардан соң барлык халыклар да ниндидер мәгънәдә оттыручы хәлендә кала.

Советлар Союзы, һичшиксез, Гитлер Германиясе җиңелүенең төп сәбәпчесе булып тора. Ләкин, кешелекне фашистлар вәхшилегеннән коткарган халыкларның язмышы нинди соң? Аерым бер мәгънәдә аларның язмышы куанырлык түгел. Әгәр немецлар ярты гасыр диярлек бер-берсеннән аерым яшәгәннән соң, берләшеп, торгызылса һәм Европа Берлегенең әйдаманына әйләнсә, сугышта җиңүче совет кешеләренең язмышы шактый катлаулы булды. СССР таркалганнан соң, андагы халыклар бүленеп бетте. Уртак Ватанны басып алучылардан бергәләп саклаган халыклар арасында хәзер яңа чикләр пәйда булды.

Бүгенге Россиянең неофашистлары һәм неонацистлар, аларның бабаларына Германия фашистлары идеологиясе никадәрле кайгы-хәсрәт алып килгәнен онытып, чыгышы белән Урта Азиядән булган халыкларны эзәрлекләргә кереште. Мөгаен, мондый аяныч нәтиҗә буласын аларның бабалары иң куркыныч төштә дә күрмәгәндер.

Бүген либераль интеллигенция вәкилләреннән дә еш кына ачыктан-ачык шовинистик шигарьларны ишетергә мөмкин. Мәсәлән, «Кавказны туендырып ятуны туктатыйк» диләр һәм



www.darul-kutub.com

Урта Азия илләре белән виза режимын кертүне таләп итәләр. Игътибар итегез, сүз Украина яки Белоруссия турында бармый, ә нәкъ менә мөселман халыклар яшәгән Урта Азия һәм Төньяк Кавказдан бүленү, читләшү турында бара.

Иң әһәмиятлесе, тарих безне нәрсәгә өйрәтә дигәндә — бернәрсәгә дә өйрәтми. Чынлыкта, мондый шигарьларны ишеткәннән соң, үз тарихын оныткан илнең киләчәге өчен кайгыра башлыйсың.

Фашизмны җиңүдә мөселман халыкларының роле бихисап зур. Советлар Союзы Герое исеменә СССРдагы барлык милләт вәкилләре дә, шул исәптән 161 татар, 96 казакъ, 69 үзбәк, 43 азәрбайҗан, 39 башкорт, 18 төрекмән, 14 таҗик, 12 кыргыз, 7 кабардалы, 6 адыгей, 5 абхазлы һәм башкалар лаек булды. Мөселманнар арасыннан 600 мең кеше яу кырында ятып калды. Ә сугышта катнашмаган никадәрле мөселман кешесе һәлак булды? Моны исәпләп чыгаруы да кыен мәсьәлә.

Шуны да өстәп әйтү мәслихәт: сугыш заманында Идел буе, Урта Азия һәм Кавказ халыклары үзләрендә Россиянең Европа өлешеннән килгән никадәр күп качакларны кабул итте, аларны ашатты һәм эчертте. Шуңа күрә Россиягә эш эзләп килгән үзбәк, таҗик һәм кыргызларны дошман сыман каршы алуларын күрү авыр тойгылар уята. Ә бит кайчандыр бу бердәм вә тату ил иде!

1942 нче елда СССРның Европа өлеше һәм Себер Диния нәзарәте фашистлар Германиясенә каршы җиһад, ягъни изге сугыш игълан итте. Ватан өчен көрәш, тышкы агрессорларга каршы тору мөселманнарның изге бурычына әйләнде. Миллионнарча мөселманнар рус, украинлылар, әрмәннәр, грузиннар, якутлар һәм чувашлар белән бер рәттә, кулларына корал тотып, ватанны илбасарлардан саклады.

Сүз уңаеннан, Бөек Ватан сугышы вакытында совет хөкүмәте дингә карашны йомшартты. Әгәр узган гасырның 30 нчы елларында коммунистлар динне әфьюн дип игълан итсә, мә-



www.darul-kutub.com

четләр, чиркәүләр җимерелеп, муллалар һәм поплар кулга алынып атып үтерелсә, илгә бәла килгәч халыкның Аллаһка, дингә мохтаҗ икәнлеге ачыкланды.

1943 нче елда Урта Азия һәм Казакъстан мөселманнары Диния нәзарәте төзелә, аның мөфтие итеп төрмәдән чыгарылган Эшон Бабахан билгеләнә. 1944 нче елда Кавказ аръягы Диния нәзарәте һәм Төньяк Кавказ Диния нәзарәте барлыкка килә. 1945 нче елда совет гражданнарына хаҗ кылырга рөхсәт ителә, Сталин Европа һәм Себер Диния нәзарәте җитәкчелегенә Ватан сугышында актив катнашкан өчен Рәхмәт хаты юллый.

Бөек Ватан сугышы чорында СССРның дин әһелләре ныклы ватанпәрвәрлек юлына баса һәм совет хөкүмәтенә Гитлер агрессиясенә каршы көрәштә булыша.

Минемчә, исламофобия, ксенофобия, мигрантофобия (кызганыч, алар җәмгыятебездә бар) фонында безгә күбрәк, Икенче бөтендөнья сугышында мөселманнар һәм православие әһелләре бергәләп ирешкән бөек җиңүебез хакында барча кеше ишетерлек итеп әйтү зарур.

Аннары Рейхстаг өстенә беренчеләрдән булып Кызыл байрак элүчеләрнең татар кешесе Гази Заһитов, дагстанлы Габделхәким Исмәгыйлев һәм казакъ Рәхимҗан Кошкарбаев икәнлеген дә онытырга ярамый.

Мөселманнар үзләренең каһарманлыгы белән Ватанның тугры уллары һәм туган илдә тынычлык вә иминлек булсын өчен гомерләрен дә бирергә әзер икәнлекләрен күрсәтте. Шуңа күрә бабаларыбызның үрнәген хәзерге заман мөселманнары да истә тотсын, шулай ук илнең башка гражданнары да безнең гомуми җиңүләребез хакында хәтереннән чыгармасын.

***Илдар БАЯЗИТОВ,***
***Татарстан мөфтие урынбасары***



www.darul-kutub.com

# ИСЛАМ — СОВЕТ ДӘҮЛӘТЕ СӘЯСӘТЕНДӘ
## *(1943-1948 НЧЕ ЕЛЛАР)*

Сугыш дәүләтнең Исламга карата мөнәсәбәтенә сизелерлек төзәтмәләр кертә. Хөкүмәт дингә элеккечә тыелгысыз басым ясау тәҗрибәсеннән баш тартып, илнең диндар халкына өлешчә ташламалар ясарга мәҗбүр була.

Дин һәм дәүләтнең кискен капма-каршылыгы дәвам иткән очракта, хезмәт тылында таркалу килеп чыгу ихтималы туа һәм хакимиятне буйсындырырга тырышып та, рухы сынмаган динле халыкның ышанычын югалта баруы куркыта. Хөкүмәт үзенең сугышчан дәһрилек сәясәтен авызлыкларга, аны Исламга карата түземлерәк мөнәсәбәткә алыштырырга мәҗбүр була. 1943 елдан хакимият дингә карата юл кую сәясәтенә күчә.

СССР Халык комиссарлары Советының 1944 ел, 19 май Карары белән СССР Халык комиссарлары Советы каршында Дин эшләре буенча Совет оештырыла. Ул, православиедән тыш, барлык конфессия — дини оешмалар, берләшмәләр җитәкчеләре һәм хөкүмәт арасындагы бәйләнешләр өчен җавап бирергә тиеш була.

Шунысын әйтеп китәргә кирәк, тикшерүчеләр, кагыйдә буларак, дини сәясәттә шушындый сизелерлек борылыш ясап ил өчен авыр булган ул көннәрдә дини оешмаларның, аның эшлеклеләренең ватанпәрвәрлек карашларын куәтләүләре белән бәйлиләр. Ислам тәгълиматының танылган белгече Т.С. Сәидбаев, мәсәлән, бу күренешкә карата гомум кабул ителгән карашларны берләштереп: «...Совет хакимиятенә карата лояль бу карашлар, аларның эшчәнлекләрендә узган гасырның 20 нче елларыннан ук урын алып, индустрияләштерү, социа-



www.darul-kutub.com

лизм төзү вакытында тагын да үскән һәм ныгыган карашларның логик йомгаклануы булды», — дип исәпли.

Чынлап та, сугыш елларында мәчетләрдә Ватанны якларга чакырулар яңгырый, фронтка киемнәр, ашамлыклар җыю оештырыла, дәүләт облигацияләре займнары таратыла, мөселманнар Кызыл Армиягә акча җыюда катнаша.

1942 нче елның май аенда ук СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең чираттан тыш киңәшмәсе үтә. Анда СССРның барлык мөселманнарына гомерләрен кызганмый Ватанны яклау турында мөрәҗәгать кабул ителә. Ул барлык мәчетләрдә дә, мөселманнарның җыелышларында да укыла.

Нәкъ менә шул мөрәҗәгать һәм динле кешеләрнең аңа карата булган фикерләре хөкүмәтне мөселманнарның лояльлегенә инандыра, һәм шуның нәтиҗәсе буларак, Исламга карата Бөек Ватан сугышы елларында дини сәясәттә борылыш күзәтелә. Мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәте мөрәҗәгате дингә мөнәсәбәт курсы үзгәрүнең тышкы бер сәбәбе була. Чынбарлыкта исә, дингә һәм дин тотучыларга карата мөнәсәбәт үзгәрүнең төп сәбәбе — СССРда динне җиңеп чыгу турындагы фикерләрнең иллюзор булуын, чиркәү белән мөнәсәбәтләрне, гәрчә күз буяр өчен генә булса да, нормальләштерү зарурлыгын аңлау була.

Хакимиятнең дингә карата сугыш елларында булган чагыштырмача лояль сәясәте, аның дин эшлеклеләренә бирелгән кайбер салым ташламалары гамәлгә керә. Аларның берсе СССР Халык комиссарлары Советы каршындагы мобилизациядән азат итү һәм кичектерү буенча комиссия тарафыннан 1945 елның 26 февралендә кабул ителгән карарында билгеләнгән. Әлеге карар буенча гыйбадәт йортларында дини йолаларны башкаручы дин эшлеклеләре хәрби хезмәткә чакырылудан азат ителергә тиеш. Бу — СССР территориясендә эшчәнлек алып барган барлык конфессия руханиларына да кагылган.



www.darul-kutub.com

СССР Министрлар Советының 1946 елның 3 декабрендә кабул ителгән «Дин эшлеклеләренә салым салу тәртибе» махсус карары буенча дин эшлеклеләренә салым күләме киметелә. 1948 елның августында алар өчен паспорт режимы да йомшартыла. Дәүләт-дин мөнәсәбәтләрен нормальләштерүдә СССР Халык комиссарлары Советының 1946 елның 28 гыйнварында кабул ителгән «Дини оешмаларның гыйбадәт йортлары турында»-гы карары әһәмиятле роль уйный. Бу карарның беренче пунктында «Дини җәмгыятьләр файдалануында булган гыйбадәт биналарын, бар диндәгеләр өчен дә, алар гыйбадәт кылу өчен арендага алган йортларны СССР Халык комиссарлары Советы каршындагы Дини эшләр Советы рөхсәтеннән башка ябу тыела» диелә. Бу — элеккеге дини мәхәлләләрне торгызырга рөхсәт итү буларак кабул ителә.

СССР Халык комиссарлары Советы каршындагы Дин эшләре буенча Совет һәм аның өлкә, республикалардагы вәкилләре гыйбадәт йортларын ачу, дини мәхәлләләр оештыру турындагы дини төркемнәрнең гаризаларын тикшерергә керешәләр. Гамәлдә исә бу яңадан теркәүгә кайтып кала.

Мәсәлән, 1945 елның 1 гыйнварына БАССРда уникe мәчет теркәлә. Аларның өчесендә бернинди дин эшлеклесе дә булмый.

Дин тотучыларның бу гаризаларын тикшергәндә, СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Советның 1947 елның гыйнварында таратылган «Гыйбадәт йортлары ачу турындагы эшләрне рәсмиләштерү» дип аталган хатка таянып эшләргә кирәк була. Тутырылырга тиешле документлар исемлеге мәчетләр ачу мәсьәләсен уңай хәл итүне шактый кыенлаштыра. Күрсәтмәләрдә, «яңа вак дини оешмалар саны артуын булдырмау өчен», гаризаларны кире кагу тәртибе дә әйтеп кителә: бинаның яраксыз, төркемнең аз санлы булуы, бинаның мәдәният, сәнәгать-оборона яки торак максатларында файдалануы, якында гына бу конфессиянең гыйбадәт йорты булуы һ. б.



www.darul-kutub.com

Хакимият органнарының гыйбадәт йортларын ачтыру, мәхәлләләр төзү турындагы гаризаларны кире кагу өчен бар нигезе дә була. Мәсәлән, Стәрлетамактагы дүрт мөселман мәхәлләсенең шәһәрдәге Кырым урамы, 33 нче йортта мәчет ачу турындагы гаризасын элек мәчет булган ул йортның балалар бакчасына әйләндерелүе, Башкортстанның Бүздәк районындагы Гафури (элекке исеме — Чукраклы) авылы мөселманнарының гаризасын «җиде чакрым ераклыктагы күрше Иске Муса авылында мәчет булуы» сәбәпле кире кагалар.

Иң күп үтенечләр 1945-1946 елларда канәгатьләндерелә. Сугыш бетүе хакимияткә дингә карата булган элеккеге лояль мөнәсәбәттән баш тартырга мөмкинлек бирә. Партиянең идеологик эшне көчәйтү турындагы 1946 елгы карары 180 градуска кире борылуны, барлык башкача фикер йөртүчеләргә, аеруча дин тотучыларга карата, элеккеге килешүләрсез басым ясауга күчүне аңлата. Идел буенда, Уралда, Мордовиядә дини җәмгыятьләрне теркәү күпкә кими.

1947-1949 елларда мәхәлләләрне теркәү кискен кими. 1948 елның апрелендә үк инде Дин эшләре буенча Совет үзенең җирле вәкилләренә «дини җәмгыятьләрне теркәүне туктатырга катгый рәвештә тәкъдим ителүе» турында күрсәтмәләр җибәрә. 1950-1954 елларда Дин эшләре буенча Совет рәхимсез карашларда тора: дин тотучыларның бер генә үтенече дә канәгатьләндерелми.

Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк: Дин эшләре буенча Советта бары тик тиешле документлары булган гаризалар гына тикшерелә, канәгатьләндерелә яки кире кагыла. Гаризаларның күп өлеше документларның тиешле дәрәҗәдә тутырылмаган булуы сәбәпле түбәндәге идарә баскычларында ук кире кагыла.

Мәләвез мөселманнарының тырышлыклары бары тик дүртенче омтылышта гына уңышка ирешә. Стәрлетамак районының Аллагувәт авылы дин тотучыларының гаризалары



www.darul-kutub.com

1946 елдан 1955 елга кадәр карала. Кайвакыт дин тотучылар Югары Советка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә — «Булганин исеменә» хат язарга мәҗбүр булалар.

Шуңа да карамастан, мөселманнар элеккечә үк дини гореф-гадәтләрне башкаруын дәвам иттерә, балаларга исем кушканда, туйлар вакытында, мәрхүмнәрне җирләгәндә дини йолаларны үтиләр, һәм, әлбәттә, мәчетләргә һәм муллаларга мохтаҗлык кичерәләр. Дин эшләре буенча Совет вәкиле хисапларында: хакимият органнары рөхсәтеннән башка дини йолаларны башкаручы төркемнәр «теркәлмәгән дини җәмгыятьләр» булып исәптә торалар, диелә. Мондый статус мөселманнарга җәмгыятьнең тиешле гыйбадәт-йолаларында катнаша алу гына түгел, ә бәлки, мөэминнәрнең төп бурычларының берсе — мәхәллә, мәчет тоту өчен акча җыярга да мөмкинлек бирмәгән.

Шулай да, кайберәүләр артта калган, надан бабайлар дип атаган дин эшлеклеләре, бернигә дә карамастан, төрле репрессияләр, кимсетелүләргә дә түзеп, еш кына, яшерен рәвештә дә, Аллаһы Тәгалә күрсәтмәләрен тараткannар һәм башкарганнар. Традицион исламга төрлечә пычрак атарга тырышкан, шул исәптән аны «бабайлар исламы» дип атаган бүгенге күпме «активистлар» шундый сынаулар астында калса, аны ничек кичерер иде икән?


***Марат МӘРДАНШИН,***
***тарих фәннәре кандидаты,***
***Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые***




www.darul-kutub.com

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## ДАНЛЫКЛЫ ҖӘЛИЛЧЕ-МАКИЗАР[1]

Җай чыккан саен, Яңа бистәдәге Татар зиратында булырга тырышам мин. Мәркәзебез Казанның хатирәләрне яңарта торган гыйбрәтле вә изге урыннарының берсе ул. Биредә милләтебезнең йөзек кашлары булган бихисап олуг шәхесләр үзләренә мәңгелек сыену урыны тапкан. Араларында үзем белгән, якыннан аралашкан күренекле әдәбият-сәнгать әһелләре дә, хәрби эшлеклеләр, сугыш һәм хезмәт каһарманнары да байтак. Зират аллеялары буйлап йөргәндә, аларның каберләре алдында кулларымны күкрәк-йөрәк турысына куеп үзем белгән догаларны укыйм...

Монда горур җанлы җәлилче-макизар Әмир Галимҗан улы Үтәшев тә (1919–1996) үзенең мәңгелек урынын алган. Генерал-майор Юныс Ибәтуллин кебек фидакарь хәрби эшлеклеләр, Рәшит Ваһапов, Ильяс Әүхәдиев кебек халкыбызның олуг мәхәббәтен казанган әдәбият-сәнгать осталары, Гыйлем Камай, Рәфгать Таһиров кебек киң танылган галимнәр янәшәсендә ята ул...

...Әмир ага белән мине туксанынчы еллар башында атаклы җәлилче якташым — нәсел тамырлары белән Мамадыш өязенең Өскебаш төбәгеннән булган мөхтәрәм Рушад ага Хисаметдинов таныштырган иде:

— ...Франциядә фашистларга каршы көрәштә зур батырлыклар күрсәткән легендар шәхес ул Әмир абыең!.. Озак еллар дәвамында хаксызга рәнҗетелгән, «оныттырылган» чын

1. Макизар — француз партизаны.



www.darul-kutub.com

каһарманнарыбызның берсе... Әйдәгез, бергәләшеп, күтәрик әле үзен — кайтарыйк илгә, халыкка данлы исемен!..

Әмир ага Үтәшев белән соңгы елларда якыннан аралашуым-дуслашуым, андагы искитмәле тарихи язмалар, Франциядән җибәрелгән, Дәүләт Куркынычсызлыгы комитеты (КГБ) архивларында дистәләрчә еллар яткан байтак документлар белән танышуым нәтиҗәсендә мин Рушад аганың батыр йөрәкле көрәштәше турында ихластан әйткән сүзләренең хаклыгына тагын бер мәртәбә тирәнтен ышандым...

Сугышка хәтле Ә. Үтәшев, Уфада кооперация техникумын тәмамлап, Татарстанның Арча районы үзәгендә, райпотребсоюзда баш бухгалтер урынбасары, аннары баш бухгалтер булып эшләгән. Фронтка да шуннан киткән. Алабугада политруклар хәзерләүче кыска сроклы курсларны тәмамлаган өлкән лейтенант Үтәшев (батальон комиссары) беренче сугышчан чыныгуны 1942 елның июне азагында Курск өлкәсендә ала. Хәлиткеч, җитди көрәшләрнең берсендә, дошман танклары белән «дуэль» вакытында ул, ике аягы да авыр яраланып, аңсыз хәлдә берничә тәүлек бомба чокырында ята. Һәм шул хәлдә дошман «тырнагы»на килеп эләгә. 1942 елның 6 июленнән аның өчен газаплы әсирлек тормышы башлана...

Баштарак фашистлар Әмир абыйны Киевта, аннары Дарница, Владимир-Волынск лагерьларында яткыралар, соңыннан Польшаның Ченстохов лагерена күчерәләр. Яралары да төзәлеп бетмәгән Әмир абый биредә тифтан егыла. Немец офицеры, аның терелүенә өметен җуеп, мәетләр барагына чыгарып ташларга боера. Әмма дөньяда яхшы адәмнәр дә бар бит әле: таныш бер әсир-санитар Үтәшевнең документларын үлгән чуваш егете Александр Николаевныкы белән алыштырып куя да, Әмир абыйны эчләре китүче авырулар ята торган баракка күчерә һәм тифтан дәвалау чараларын күрә. Шулай итеп, Әмир Үтәшев Александр Николаев (Франциядә «Александр Николас», «Капитан Александр») булып китә. Фран-



www.darul-kutub.com

цузлар биргән барлык документларда аның исеме алга таба «Әмир» дип түгел, «Александр» дип телгә алына...

1943 елның маенда Ә. Үтәшевне Польшаның Едлинодагы хәрби әсирләр лагерена — «Идел-Урал» легионына китерәләр. Биредә ул, Рәхим Саттар, Әкрам Мамлеев ярдәмендә, Муса Җәлил белән якыннан таныша һәм биредәге яшерен оешманың ныклы әзерлекле бер әгъзасы булып китә.

— ...Легионда синең яшерен эш алып баруыңның төп максаты — үзебезнең ватандашларны, ничек кенә булса да, партизаннар ягына алып чыгып, фашистларга каршы бергәләп көрәшү булырга тиеш! — ди Муса Әмиргә. — Мин сиңа ышанам: башлаган эшебезне дошманны тәмам җиңгәнчегә кадәр дәвам ит... Дөнья бит бу, безне алда нәрсә көткәнен бер Аллаһ үзе генә белә...

Күңеле дөрес сизенгән икән шагыйрьнең. Озак та үтми, 10 августта, фашистлар М. Җәлилне һәм яшерен оешма әгъзаларының бер өлешен кулга алып, зинданнарга ташлыйлар. 1943 елның августында «Идел-Урал» легионының Көнчыгыш фронтка җибәрү өчен әзерләнгән өченче (штаб) батальонын, ашыгыч рәвештә ике эшелонга төяп (писарь Әмир Үтәшев тә шунда була), немецларның көчле сагы астында, Франциянең Югары Луара департаментындагы Ле-Пюи шәһәренә озаталар (чөнки баштагы беренче, икенче батальоннардагы легионерлар, фронт сызыгына килүгә үк, немец офицерларын юк итеп, Витебск өлкәсендә һәм Көнбатыш Украинада партизаннар ягына чыккач, гитлерчылар тирән пошаманга төшә). Җәлилчеләрнең Франциядәге яшерен оешмасы җитәкчесе буларак, Ә. Үтәшев тиз арада француз партизаннары — макизарлар белән элемтәгә керә һәм легионерларның, бераздан немецларны коралсызландырып, французларның Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә бердәм рәвештә кушылуларын тәэмин итә. Бер үк вакытта Совет Армиясе офицеры да, Франция Эчке Көчләре капитаны да, татар һәм рус партизаннарының



www.darul-kutub.com

беренче группасы җитәкчесе дә булган Әмир абый (французлар аны, хөрмәтләп, «Комбатан Волонтер» дип йөртәләр, үзләренең иң зур орденнары белән бүләклиләр), ике меңгә якын легионерны, макизарны Туган илгә исән-имин кайтаруда да һәм җәлилчеләрдән Габбас Шәрипов, кан кардәше, авылдашы Нигъмәт Терегулов, француз патриоткасы Мария Дебиезе белән берлектә, дөньяны тетрәткән «Моабит дәфтәрләре»нең беренчесен саклап калуда да чын егетлек күрсәтә. (Безнеңчә, аларның һәркайсына — хәтта кайберләре инде үлгән булса да! — Россия, Татарстан хөкүмәтләре тарафыннан тиешенчә бәһа бирелергә тиеш. Әнә бит, Бельгия гражданины Андре Тиммермансны, «Моабит дәфтәрләре»нең икенчесен саклап калганы өчен, Совет хөкүмәте 1966 елда «Батырлык өчен» медале белән бүләкләде!)

Ә. Үтәшевне дә «бүләклиләр». Тик — башкача. 1945 елның 1 сентябрендә Әмир Галимҗан улын — Франциядәге ватандашларын Туган илгә алып кайтучы эшелон җитәкчесен — совет-герман чигендә армия контрразведкасы кулга ала. Хәрби трибунал башта аны «Ватанга хыянәт иткән өчен» атарга хөкем итә, бераздан бу карар 25 елга иректән мәхрүм итү — каторга белән алыштырыла... Гаделлек, чын дөреслек тантана итсен өчен бик озак көрәшергә туры килә бу батыр йөрәкле, курку белмәс ир-атка. Үзеннән бигрәк, бер гаепсезгә төрмәләргә ябылган, лагерьларга озатылган сугышчан дуслары өчен борчыла, газаплана ул. Фашизмга каршы бергәләп көрәшкән иптәшләренең намуслы исемнәрен кире кайтарырга булышу, инде вафат ветераннарның якыннарына легионер-макизарлар турында чын хакыйкатьне ачу өчен, Әмир ага 1990 елның августында француз теле белгече Надежда Татаренко (Казан) белән бергә махсус рәвештә Франциягә, Баинс, Ле-Пюи шәһәрләренә барып, якташларыбызның каһарманлыкларын раслаучы үтә мөһим документлар алып кайта...



www.darul-kutub.com

Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтик: Франциядә аны, зурлап, милли Герой итеп каршылыйлар! Югары Луара департаментының «Трибуна» газетасы 1990 елның 3 август санында «46 ел узгач, Россия макизары Баинс янында сугышлар барган урында» дигән мәкаләсендә болай дип яза:

*«...Бу пәнҗешәмбедә Баинс шәһәренең мэры Мишель Декольн әфәнде, Казан кунагы Александр Үтәшевне аэропортта каршыларга дип, Парижга китте. Ярты гасырга якын вакыт узганнан соң, Россия солдаты кайчандыр сугыш кыры булган урыннарга, өч ватандашы күмелгән Вержезак зиратына әйләнеп кайта. Аның кайтуы Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә, дөресрәге, Баинс янындагы сугышларга бәйләнгән. Бу хакта, Фернан Буатенең «Түгелгән канның таш шаһитлары» дигән китабын укып, төгәлрәк мәгълүматлар алырга була.*

*...Ле-Пюига килеп урнашкан һәм Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашучыларга каршы сугышырга тиешле немец гарнизонында хәрби рус әсирләре дә була. Дөресрәге, легионга көчләп кертелгән, җирле халык «монголлар» дип атаган татар әсирләре алар. Каршылык күрсәтү хәрәкәте ныгый барган шул чорда йөзләп әсир, гарнизоннан качып, Ружак һәм Иссенжо районнарында капитан Сегель җитәкчелегендәге макизарларга барып кушыла. Немецларга каршы Баинс шәһәре өчен барган сугышта һәлак булган алты партизанның да өчесе — элекке легионерлар. Менә алар кемнәр: Андрей Аксенов — очучы, капитан; Газизҗан Зөбәеров һәм билгесез солдат...*

*Ул сугышта исән калганнарның берсе — Александр Үтәшев. Легионнан качып, ул Каршылык күрсәтү хәрәкәте алып барган көрәшләрдә бик нәтиҗәле катнаша...»*

Шул ук газетаның 13 августта чыккан санындагы «Баинс: 1944 елгы сугышны искә алу» дигән язмага да күз салып үтик:

*«...Баинста һәлак булганнар монументы янына ике йөзләп кеше җыелды. СССРдан капитан Александр Үтәшев килү сәбәпле, быелгы тантана аеруча истәлекле узды. Каршылык күр-*



www.darul-kutub.com

*сәтү хәрәкәте ветераннары элеккечә олы кунак янәшәсенә туплandылар...»*

«Левэй» газетасы шул ук елның 14 август санында чыккан «Каршылык күрсәтү хәрәкәте сугышчылары Александр Үтәшев янында» дигән мәкаләсендә, Әмир ага турында сүзне дәвам итеп, түбәндәгеләрне яза:

*«...Ле-Пюидагы яшерен оешма җитәкчесе Үтәшев СССРда 8 ел буена лагерьларда утырып чыкканнан соң гына реабилитацияләнә. Хәзер инде ул үзенең көрәштәш ватандашларын аклау чараларын эзли...*

*Һәлак булган иптәшләренең каберләренә чәчәк бәйләмнәре куйгач, карт солдат күз яшьләрен тыя алмады...*

*Һәйкәл янында соңгы сүзне Генераль совет вәкиле Прориоль әфәнде әйтте. Ул Үтәшев әфәндегә, көчле рухлы, изге-якты күңелле шәхес булганы һәм Францияне дошманнан азат итүдә турыдан-туры катнашканы өчен кайнар рәхмәт белдерде. «Сугыш Сезне бу якларга элек көчләп, мәҗбүри итеп китергән булса, бүгенге иминлек Сезне безнең департаментта олы кунак сыйфатында кабул итәргә ярдәм итте», — диде ул...»*

* * *

Франциядән кайткач, Әмир ага Үтәшев радио-телевидение тапшырулары, газета-журнал битләре аша чыгышлар ясап, Идел-Урал төбәкләрендәге хәрби комиссариатлар, Дәүләт Куркынычсызлыгы комитеты вәкилләре белән элемтәгә кереп, үзенең сугышчан дусларын, легионер-макизарларны эзләүгә тагы да ныклап кереште...

1991 елның 24 декабрендә Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев белән дә очрашты ул. Бу көнне бирeдә Алманиянең Плетцензее төрмәсендә 1944 елның 25 августында көндезге 12 сәгать 06 минуттан 12 сәгать 36 минуткача вакыт эчендә фашист гильотинасында



www.darul-kutub.com

башлары киселгән унбер татар каһарманын зурлап искә алу, шуларның унысына, дөресрәге, якыннарына, I дәрәҗәле Ватан сугышы орденнарын тапшыру тантанасы үткәрелде.

* * *

1993 елның 21–24 апрель көннәрендә Ә. Үтәшев, Франциядә фашистларга каршы көрәшкән легионер-макизарларның Беренче халыкара конференциясендә дә катнашып, эзләнүләрен тагын да киңрәк җәелдереп җибәрү өчен зур мөмкинлекләргә ия булды. Шул ук елның 6 маенда, Татарстан Дәүләт милли музеенда җәлилчеләргә багышланган искә алу җыенында, Әмир аганың тырышлыгы белән, Каршылык хәрәкәтендә катнашучыларның «Кызыл ромашка» исемле ассоциациясе төзелде. Оешманың рәисе (президенты) итеп бертавыштан аның үзен сайлап куйдылар. Әлеге ассоциация Идел буе, Урал төбәге республика-өлкәләрендә яшәүче элекке легионерларны, макизарларны, хәрби тоткыннарны, партизаннар хәрәкәтендә катнашучыларны үзенә берләштерде.

Әмир Галимҗан улының турыдан-туры булышлыгы белән легионер-макизарлардан байтак кешегә намуслы исемнәре кире кайтарылды, хәрби бүләкләре тапшырылды. Ул йокыялын онытып, көрәштәш дусларының язмышларын җиңеләйтү өчен, югары оешмаларга бихисап хатлар язды, аларның чын патриотлар икәнлеген раслаучы тарихи документларны туплап җибәрде, кирәк икән — теге яки бу төбәккә үзе үк барып кайтты. Әйтик, Татарстанның Буа районындагы Янтуган авылында яшәүче легионер-макизар — француз партизаннары отрядында данлыклы старшина булган Ибраһим Айнатулла улы Айнатулловны һаман да сугыш ветераны итеп санамауларын-санламауларын белгәч, ул, барлык эшен ташлап, юллар өзеклегенә, язгы ташуга карамастан, 1992 елның март азагында — апрель башында шул төбәккә барып чыкты. Би-



www.darul-kutub.com

редә ул сугышчан дусты турында район һәм хуҗалык җитәкчеләре белән очрашып сөйләште. Авыл халкы, укытучылар һәм укучылар катнашында аңа багышлап мәктәптә зур кичә үткәрде. Шуннан соң гына Ибраһим аганың кәефе дә, абруе да бердән күтәрелеп китте. Гомере буе туган ягында шофер һәм янгын сүндерүче булып намуслы хезмәт иткән, сөекле хәләл җефете — Хәтирәсе белән берсеннән-берсе булдыклы егетләр, уңган кызлар тәрбияләп үстергән ветеранның иңнәренә пар канатлар үскәндәй булды шул истәлекле, дулкынландыргыч очрашулардан соң…

Республикабызның Кукмара районындагы Зур Сәрдек, Ташлы Елга, Ятмас Дусай авылларында яшәүче Гаян Әхмәтшин, Нургали Шәйдуллин, Галимҗан Әхмәтҗанов, Әтнәдән Мөбарәкша Хәсәнов, Азнакайдан Гомәр Асибаков, Баулыдан Петр Долгов, Буадан Фазыл Хәйруллин, Казаннан Ризван Мөхетдинов, Башкортстанның Туймазы, Октябрьск, Уфа шәһәрләреннән Фәйзерахман Закиров, Әлмөхәммәт Низаметдинов, Әкрам Минһаҗетдинов, Әстерханнан Хәбибулла Моратов кебек дистәләгән легионер-макизарларны аклау, аларның намуслы исемнәрен кайтару буенча да ныклап шөгыльләнде Әмир ага. Бу эшләрнең һәммәсендә аңа кешелекле һәм уңган хатыны — якын дусты һәм киңәшчесе Рәйсә ханым, үз мәктәпләрендә «Иң яхшы мөгаллимә» буларак танылган кызлары Әлфия, оныгы — яшь шагыйрә Кадрия бик теләп булыштылар.

1995 ел азагында Әмир аганың тормышында тагын бер истәлекле вакыйга булды: ул Франция хөкүмәте билгеләгән махсус пенсияне ала башлады! Идел-Урал төбәгендә яшәүче элекке макизарлар арасында беренчеләрдән булып… Әнә шулай, киң күңелле, олы җанлы французлар үз Ватаннарының азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшкән «комбатан Волонтер»ны — инде сугыштан соң күп еллар үтсә дә! — онытмыйлар. Әмир ага Үтәшев турында кайгыртып, 1995 елның



www.darul-kutub.com

апрелендә Казанга Франциянең Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Пьер Морель әфәнде махсус килеп киткән иде. Пенсия өчен кирәкле документларны да шул чорда хәзерләтеп алган иде ул. Рәхмәт үзенә — сүзендә торган!

Үләренә берничә ай кала, Әмир ага Казан — Чаллы — Азнакай — Баулы — Октябрьск — Туймазы — Бүздәк — Уфа — Казан маршруты буенча йөреп кайтты. Үзенең көрәштәш дуслары, легионер-макизарлар һәм аларның гаилә әгъзалары, якын туганнары белән очрашты ул. Аңарчы Әмир ага Франциянең Баинс шәһәре янында барган сугышларда батырларча һәлак булган дусты — үз отряды сугышчысы Газизҗан Зөбәировның гаиләсе янында — Башкортстан Республикасының Кыйгы районында булып, алар белән рухи туганлашкан иде...

Әмир ага Үтәшевне рәхимсез авыру (инфаркт-инсульт) 1996 елның 21 гыйнварында, башка кузгала алмаслык итеп, урынга екты. Бөтен гомере тоташ батырлыктан, ялкынланып янудан торган олпат ир-атның — Әмир Галимҗан улы Үтәшевнең күпне кичергән тынгысыз йөрәге изге Рамазан аеның 16 нчы көнендә (6 февраль) тибүдән туктады... 77 яшен дә тутырырга өлгермәгән олуг милләттәшебезне, зур кадер-хөрмәт күрсәтеп, Казан каласының Яңа бистәдәге мөселман зиратында җирләдек...

***Шаһинур МОСТАФИН,***
***эзтабарларның «Хәтер яктысы»***
***берләшмәсе җитәкчесе,***
***Россия Хәрби-тарихи фәннәр***
***академиясенең мөхбир-әгъзасы***



www.darul-kutub.com

# ПРЕДСМЕРТНЫЙ КОРАН:

## ТАЙНА ГИБЕЛИ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ И ЕГО СОРАТНИКОВ

**Воспоминания Усмана, сына Галима, записанные Анваром Галимом**

«Попасть в заключение по политическим мотивам в любой стране, тем более в военное время, — тяжелое испытание. Ни одно государство не терпит действий, направленных против него. Именно поэтому я предполагал, что положение Мусы и его товарищей не будет легким. Так оно и вышло. Когда их расстреливали, меня тоже вызвали как мусульманского священнослужителя.

Я не могу забыть тот день. Да его и невозможно забыть. 20 августа прошлого года (1944) меня позвал Шафи и сказал: «25 августа приведут в исполнение смертный приговор для Мусы и его товарищей, необходимо твое присутствие, об этом сообщил Главный Муфтий». В тот день рано утром я пошел в тюрьму Плетцензее и сначала поговорил с тюремным пастором. Пастор обрадовался моему приходу. Он сообщил мне, что татары будут расстреляны в 12 часов. По словам пастора, приговоренные к смерти татары находятся в одной большой комнате, и им не верилось, что их расстреляют. Пастора они всегда принимали тепло и высказывали ему свои жалобы.



*Предсмертный Коран Мусы Джалиля и фото муллы Усмана*



www.darul-kutub.com

Около 11 часов мы с пастором зашли к приговоренным татарам. Так как приговоренных к смерти узников я посещал впервые, я растерялся, не знал, что сказать... Мне казалось, что любое мое слово придется не к месту. Все и так понятно: все поникли, все в растерянности, в смятении. Когда я вошел, все, подняв головы, посмотрели на меня. Мне показалось, что им со мной говорить не хотелось... Ожидание последних минут жизни было бесконечно тяжело. Меня охватила дрожь, сначала меня бросило в холод, потом в жар.

Первым я протянул Коран Алишу и что-то ему прошептал (сам не помню, что именно). Он медленно встал, положил руку на Коран и заплакал. Все испытывали душевные муки. Говорю душевные, так как, по словам пастора, заключенных не подвергли такому варварству, как избиения и пытки.

Я подошел к Гарифу Шабаеву и протянул ему Коран. Когда он положил руку на него, я спросил: «Не пытали?» Он ответил: «Нет, пыток не было». Я подходил ко всем, протягивал Коран, и все, положив руку на него, говорили: «Прости, прощай» (тат. — «Бэхиль, бэхиль» прим.пер). Ахмет Симай, положив руку, сказал: «Усман эфенди, мы не ожидали, что будет так, не ожидали». Последний, к кому я подошел, был Муса. Я протянул ему Коран. Он, положив руку, прошептал: «Прощайте, это судьба, мы не думали, что нас убьют». Среди них были еще два человека, которых я не знал, должно быть, это были легионеры...».

***

Вот о чем рассказал Усман, сын Галима, — продолжает Анвар Галим. Затем я спросил: «Расстреляли или повесили?» «Расстреляли, — сказал он, — у меня в кармане Коран, клянусь Кораном: их расстреляли. Потому что, — говорил он, — они военные, военных не вешают, военных расстреливают,



www.darul-kutub.com

это во всех странах так...». Подумав немного, он добавил: «Я думал, что Муса и его товарищи не примут меня, муллу, не станут разговаривать из-за того, что они коммунисты. Видимо, их коммунистические убеждения были повержены (тат. коммунистлыгы жинелде — досл. коммунизм побежден — прим. пер.)».

Слова муллы Усмана были для меня новостью. Я хотел побольше расспросить его об этом, да как-то не смог: губы мне не повиновались. В этот момент вошла госпожа Луиза (супруга муллы Усмана, по национальности немка — прим. авт.) и позвала муллу Усмана обедать. Я, низко склонив голову, вышел...

## КОММЕНТАРИИ

Многие, прочитав эти воспоминания, могут подумать, что Мусу и его товарищей расстреляли, а не отрубили головы. Как тут не поверить, ведь сам мулла поклялся Кораном! Однако не будем торопиться с выводами, давайте-ка поразмышляем вместе.

Сам мулла Усман во время исполнения казни не присутствовал. Он лишь предполагает. «Потому что, — говорит он, — они ведь военные, военных не вешают, военных расстреливают, это во всех странах так...». И глубоко ошибается. В фашистской Германии, особенно с июля 1944 г., после покушения на Гитлера, военных наказывали по-разному: и расстреливали, и вешали, а иногда отрубали головы. (Именно так поступили с теми, кто покушался на фюрера.)

Тюремный пастор, о котором упоминал мулла, пастор Юрытко, остался жив. Я за много лет до этого переписывался с ним. Хотя он сам не присутствовал при казни, он хорошо помнит Мусу и его товарищей. По его словам, их повесили.

Такие различные версии естественны, потому что гитлеровцы никого близко не подпускали во время казни. Эта мер-



www.darul-kutub.com

зость осуществлялась закрыто. Место казни — одноэтажное угрюмое здание (оно сохранилось до сего дня) — расположено чуть поодаль от тюремного двора Плетцензее. Там заключенных и расстреливали, и вешали, и отрубали им головы.

А раз так, единственным источником, которому можно доверять, остается только документ, акт, составленный самими палачами. Оригиналы этих документов по сей день хранятся в архиве тюрьмы Плетцензее. Никто не выражал сомнения по поводу их подлинности. Согласно этим документам, джалилевцев казнили, отрубив им головы на гильотине 25 августа 1944 г. между 12.06 и 12.36.

Второй каверзный вопрос касается веры Джалиля и его товарищей в Аллаха. Мулла Усман считает, что они могли не принять муллу и не говорить с ним из-за того, что они коммунисты. Но после того, как осужденные попрощались, положив руки на Коран, он делает вывод: «Видимо, их коммунизм побежден». Кстати, именно этот факт и мешал выходу в свет этих воспоминаний. Мы, подчеркивая мужество и героизм джалилевцев, с одной стороны, оказывается, совсем забыли о другой стороне. Да, они действительно держались мужественно, вели неустанную борьбу с фашистами в самых тяжелых условиях. Они тайно организовали общество, распространяли листовки. (В воспоминаниях Анвара Галима об этом тоже говорится.)

Но ведь они тоже живые люди! Все они были молодыми, примерно в возрасте 25-27 лет, и все предстали перед смертью. Самому старшему среди них, Мусе, было 38 лет. Естественно, что перед смертью люди оказываются в растерянности, в смятении, подавленности, прощаются с жизнью с Кораном в руках... Это их слабость или человечность? Видимо последнее...

Нельзя забывать и том, что мать Мусы Джалиля Рахима апа была дочерью муллы. В их доме в деревне Мустафино Орен-



www.darul-kutub.com

бургской области помимо Корана было много религиозных книг. Поэтому Муса с детства воспитывался в духе ислама. В Оренбургском медресе «Хусаиния», как и все, он изучал религиозные предметы и, по словам его товарищей, знал наизусть некоторые суры Корана. Действительно, в советскую эпоху Джалиль был комсомольцем, затем вступил в Коммунистическую партию, отрекся от религии, выступал против нее. Однако в час смерти он вернулся в религию, видимо, вера все же в нем жила, несмотря на внешнее отречение.



*Муса Джалиль и его соратники*

Здесь нужно сделать еще одно пояснение. Мулла Усман, полагаясь на слова пастора, говорит, что грубого отношения к заключенным, избиения или пыток не было. Даже Гариф Шабай на его вопрос ответил: «Нет, пыток не было». Возмож-



www.darul-kutub.com

но, в свое время мы слегка приукрасили эту сторону. В действительности же было по-разному: кого-то били, кого-то пытали, кого-то нет. Многие видели, что Муса возвращался с допросов избитый, изможденный. Я своими глазами видел красные полосы от кнута на спине Рушата Хисаметдинова, который был арестован вместе с Мусой и чудом остался жив. Многое зависело от того, кто и как себя поведет, к какому следователю попадет…

Мулла Усман сказал: «Среди них были еще два человека, которых я не знал, должно быть, это были легионеры…». Действительно, помимо джалилевцев, которых он знал, с кем встречался и общался, были еще два человека из легиона. Узнать их имена помогли те же документы: Ахат Атнашев и Салим Бухаров.

После смерти муллы Усмана упомянутый Коран находился сначала в Германии, затем перешел на хранение в руки татар, живущих в Америке. В дни Первого Всемирного конгресса татар эту священную книгу привез в Казань наш соотечественник и передал в руки известного ученого Миркасыма Усманова. Он передал книгу в музей Мусы Джалиля. Сейчас Коран является самым ценным экспонатом музея.

*Рафаэль МУСТАФИН,*
*писатель*



www.darul-kutub.com

# ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК
## ФРОНТОВИК ХАТИРӘЛӘРЕ

***Салихов Харис Салих улы (Харис Салихҗан) 1927 елда Татарстанның Балтач районы Чутай авылында туа. Авыл мәктәбендә укыган вакытында әтисе аны ислам гыйлемнәренә һәм гарәпчә укырга өйрәтә. Чутай җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң Арча педучилищесына укырга керә. 1944 елда фронтка китә. Яу кырында күрсәткән батырлыклары өчен Ватан сугышының II дәрәҗәле Ордены һәм 20дән артык медаль белән бүләкләнә. Сугыштан соң Мәскәүдә һәм Казанда хокук саклау органнарында эшли. Гадел һәм профессиональ юрист буларак танылa. 1972 елда Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән. Публицист А. Станислав сүзләре белән әйтсәк: «Малай һәм сугышчы; коммунист һәм мөселман; милиционер һәм имам, мөфти урынбасары; крестьян малае һәм профессор атасы; куылган һәм танылган; гади шәхес һәм теолог. Академик, Россия гуманитар фәннәр академиясенең шәрифле әгъзасы — болар барысы да бер кеше, аксакал Харис Салихҗан язмышына сыйган».***

***Харис абый бүген дә актив, аның һәр көне зур түрәләрнеке сыман минуты-сәгате белән планлаштырып куелган. Шул планга «төзәтмә» кертеп, мөбарәк җомга көннәренең берсендә мөхтәрәм шәхесебез Харис хәзрәт Салихҗан белән очрашып сугыш хатирәләрен тагын бер кат хәтердә яңартып алдык. Максатыбыз Бөек Ватан сугыш елларында дингә нинди мөнәсәбәт булуын шушы олы афәтнең тере шаһите булган имамыбызның үз авызыннан сөйләтү иде...***



www.darul-kutub.com




## «АЛЛАҺ ДИГӘН СҮЗ ЧЫГАРМА, ТӨРМӘГӘ ЯБАРЛАР»

Сугыш вакытында динне тыю булмады. 43-45 елларда бер генә частьтә дә ( ә мин НКВД частендә идем) бер генә кеше дә тыймады аны. Хәрби җитәкчеләр арасында Аллаһка мөрәҗәгать иткән, дога кылган кешене түбәнсетү дә, шул ук вакытта дога кылыгыз әле дип әйтүче дә булмады.

Унҗиде яшем тулганда — 1944 елны мине армия сафларына чакырып алдылар. Бер үземне генә түгел. Авылыбызның бөтен яше-карты безне сугышка озатып калды. Ул чактагы елашулар кичә генә булган шикелле. Әби миңа: «Бишмәтеңә «Ясин» сүрәсен тектем, югалта күрмә», — дигән иде. Дөрестән дә, мин аны югалтмадым, ул әле хәзер дә саклана… Яу кырында ярты ел гына булган кешемен, әмма аның һәр көне — йөрәктә.



www.darul-kutub.com

1945 елның март аенда Венгриядә каты сугышлар булды. Без НКВД гаскәре — гел алгы сафта. Үлем белән күзгә-күз очрашабыз. Балатон күле янында безне 3 сәгать тоташ бомбага тоттылар. Аны сүз белән генә әйтә, аңлата торган түгел. Фашист шулкадәр явыз, Гитлерның сайлап алынган гаскәре белән сугышабыз.

...Сазлыктагы түмкәкләр арасына кереп яшеренергә мәҗбүр булдык. Башны гына чыгарып ятабыз. Суык. Фашистлар безне бертуктаусыз бомбага тота. Иманы көчәеп китте күрәмсең, Сәгъдулла исемле иптәш малай: «Яшьтәш, үтерәләр бит, әйдә, укы әле», — диде. Мин укыйм. Әлхәм сүрәсен укыйм. Сәгъдулла тагын «укы!» ди, мин тагы укыйм... Укы да укы, диләр. Хәлем бетте, укый-укый арып та беттем. Аллаһының рәхмәте, безнең отделениедән берәү дә үлмәде, Кәримов Нургаян исемле солдатның гына аягы яраланды. Ә үлүчеләр бихисап күп иде. Әлеге вакыйгадан соң татар малайлары сизеп алды укысаң исән каласың икәнлеген. Хәтта моңа кадәр бөтенләй ышанмый йөргәннәре дә. Бу хәлдән соң болар күбрәк минем янга сырыша башлады.

Һәр сугышка керер алдыннан Сәгъдулла да, Нургали дә, башкалар да «укы!» диләр иде. Вена операциясе алдыннан Сәгъдулла әйтә: «Әйдә, яшьтәш, намаз укыйк», — ди. Бөтен бер фронт яуга әзерләнгән вакыт бу. Без, сугышка әзерләнүчеләр — 17 яшьлек, 40-50 килолы малайлар инде. Күбебез русча да рәтләп белми. Дөресен әйтергә кирәк, безне килүгә үк өлкәнрәкләргә беркеттеләр. Русларга. Алар барысы да йә коммунист, йә комсомол.

Вена операциясендәге бурычыбыз алдагыларына караганда катлаулырак иде. Әзерлегебезне тикшереп карарга булдылар. Ә без — радистлар. Сәгъдулла радиостанция белән эшли алмады, каналга керә алмады. Старшина әйтә: «Син бит бернәрсә дә белмисең. Запас полктан үттеңме?» — ди. «Үттем», — ди Сәгъдулла. «Анда нишләдең?» — ди. «Шапком каша ку-



www.darul-kutub.com

шал», — ди бу. Запас полкта һәр солдатта кружка, кашык бар, ләкин савытлар юк иде. Чиләк белән аш алып киләләр. Аны кружкага салып бирәләр. Гел су гына инде ул, аш дип аталса да. Бер үк вакытта «икенче блюдо» дигәнен дә тараталар, ә анысын салырга урын юк. Шул сәбәпле без бүрекләрне тезеп куя идек. Аңа бер кашык тары боткасы салалар. Үз бүрегеңдәгесен ашамыйсың әле, башка солдатныкы эләгә... Шуңа күрә дә Сәгъдулла «шапком каша кушал» диде старшинага.

Хаклыкны әйтергә кирәк, безнең гаскәрдә сайлап алынган кешеләр, бары тик комсомоллар һәм коммунистлар гына тупланган иде. Иң түбән белем — 9 класс. Без мөселманнар бит. Киткәндә әти миңа бик нык кисәтеп: «Аллаһ дигән сүз чыгара күрмә, төрмәгә ябып куярлар», — дигән иде. Шулай ук: «Үзеңә кыен чакта гына түгел, һәрвакыт Аллаһка ялвар, дога кыл!» — дип тә нәсыйхәт бирде. Әтинең шул сүзләрен гел күңелдә тоттым.

## НАМАЗ УКЫСАҢ — ҮЛМИСЕҢ!

Апрель аенда Вена операциясендә катнаштык. Без бер батальонда 30лап татар малае идек. Әйткәнемчә, малайлар: «Әйдәгез, операция алдыннан намаз укыйк», — диделәр. Һәр солдатта плащ-палатка бар, намазлык урынына шуны җәябез. Мин — имам. Малайлар мин нишлим, шуны эшли. «Намаз укысаң, үлмисеңме?» — диләр. Мин әйтәм: «Үлмисең. Ихлас ят та, Аллаһтан сора». Сәҗдәгә яткач малайлар «йә Аллаһ, йә Аллаһ...» дип елыйлар. Бик җитди хәрби операциягә әзерләнәбез бит. Бертуктаусыз комсомол җыелышлары бара. Бертуктаусыз үгетләү бара. Бертуктаусыз аңлату бара... Сугышырга өйрәтәләр. Ә без намаз укыйбыз шушы өйрәтүләрдән бушаган арада. Командирларга күренеп түгел инде, әлбәттә, качып кына. Кая инде ул күрсәтеп гыйбадәт кылу?! Берсендә мине өлкән сержант Сорокин күреп алды:

Кил әле монда. Фамилияң ничек? — диде.



www.darul-kutub.com

— Кызылармеец Салихов.
— Сез нишлисез анда?
— Кайда?
— Куаклар арасында нәрсә пышылдыйсыз?
— Намаз укыйбыз.
— Нәрсә ул намаз?
— Намаз — ул мөрәҗәгать.
— Кемгә?

Эчтән генә әйтергә уйлыйм, Иосиф Виссарионович Сталинга дип. Әмма күңелне «шәп чыкмас бу» дигән уй били. Ә Аллаһка мөрәҗәгать итәбез дип әйтергә куркам. Шулай ни әйтергә белми тордым да, бармагымны күккә күтәреп:

— Әнә, анда, өстә утыручыга, — дидем.
— Богу что ли?
— Так точно. Богу.

Шуннан соң, Аллаһның рәхмәте, бу миңа:

— Ә нәрсә сорыйсыз? — диде.
— Без, иптәш Сорокин, кызылармеец Салихов операция вакытында үлмәсен дип сорыйбыз.
— «Тагын нәрсә сорыйсыз?» — ди бу. Мин берәмләп бөтен татар малайларының исемен атап чыкканнан соң: «Пашка үлмәсен дип тә сорыйбыз, дөрес, аның алласы бүтән», — дидем. Миңа аптырап карады да: «Ничек бүтән?» — ди. Мин аңлатып күрсәттем инде русларның үз алласы, татарларның үз алласы булуын. Ә ул миңа «Яхшы итеп исеңдә калдыр, синең үз аллаң юк! Сезнең Аллаһ та, безнең бог та бер үк затны аңлата» димәсенме?! Менә сиңа өлкән сержант, коммунист! Ул һаман төпченүен дәвам итте әле. Шуннан соң мин аңа: «Ә без тагын операция вакытында иптәш Сорокин үлмәсен дип тә сорыйбыз», — дидем. «Чынлапмы?»— диде дә елый башлады. Мине кочаклап елады.

Урыс малайларының Библиядән язып алынган догалары бар иде. Ә кайберләре кесәләрендә икона да йөртте. Шуны



www.darul-kutub.com

кулларына алып «спаси нас бог» дип дога кылалар иде. Мин: «Ничек безгә дин мәсьәләсендә ирек бирәләр икән?!» — дип аптырый идем. Бер кеше тыймый, әле яклыйлар да.

## ӘЙДӘ, «ЯСИН»НЕ УКЫ

...Вена операциясендә безнең бурыч — операция башланганчы 5-6 сәгать алдан Дунайны кичеп чыгып, плацдарм алу иде. Иллеләп көймә. Һәр көймәдә 15тән артык солдат. Дунай елгасын кичәргә тотынган идек кенә, немецлар безне бомбага тота башлады. Без тиз-тиз ишәбез көймәне. Бомба йә алга төшә, йә янга, йә артка. Малайлар миңа «укы, укы» диләр. Мин укыйм да укыйм. Ярга чыгып җитәргә йөз метр чамасы калгандыр көймәбез башына мина төште дә кире әйләнеп капландык. Без су астыннан йөзеп чыгып аның сыртына ябыштык. 18 малай идек. Икебез юк. Мин — отделение командиры. «Иптәш кызылармеецлар, паникага бирелмәгез, хәзер безнең бурыч — гомеребезне саклау!» дип әмер бирдем. Кычкырып-кычкырып «Паникага бирелмәскә!» дигән сүзләрне кабатлыйм. Көймәгә ябышкан хәлебездә Дунай буйлап агып барабыз. Менә күп тә үтмәде атыш арасына килеп кердек. Бер яктан фашистлар ата Совет солдатлары дип, ә икенче яктан, немецлар дип уйлап, безнекеләр. Менә шунда чын паника башланды. Ун минутлап барды бу хәл. Бер генә солдатыбыз югалды. Ничек төшеп киткәнен күрми дә калдык. Караңгы төн. Салкын дулкын дәһшәт белән безгә китереп бирә...

Тагын хәрби зонадан чыктык. Атыш бетте. Агабыз да агабыз. Сәгать ярым — ике сәгать тирәсе аккач, хәлебез бетте. Бармаклар, куллар кабарып чыкты. Туңа башладык. Көймә сыртына тотынган килеш агабыз бит. Тотынырлык урыны да юк рәтләп. Күңел төшенкелегенә бирелеп бер малаебыз елый башлады. Аңа кушылып мин дә елый башладым. Нәнәй җаным, үләбез, нәнәй җаным, үләбез, дим эчтән генә. Шул



www.darul-kutub.com

чак Сәгъдулла китереп орды теге малайга. Паника ясыйсың монда дип. Тотып ыргытам мин сине Дунайга, ди. Мин — командир, мин тыярга тиеш, югыйсә. Шып булдым. Миңа: «Син еларга тиеш түгел, нинди командир синнән?!» — ди. Бу хәлдән соң акыл керде безгә. Күпмедер вакыттан соң тагын бер малаебыз юкка чыккач, Сәгъдуллага әйтәм: «Әйдә, каешларны башка бәйлик», — дим. Ике кешене тоташтырырлык итеп, каршы як белән башны башка якынайтып каеш белән муеннан бер-беребезгә бәйләндек. Дулкын китереп бәргәндә төшеп китмәскә, ныграк тотынып торырга шәп мөмкинлек булды ул. Без барыбер үләсебезне беләбез инде. Бик каты туңдык та... Күңеле төшкәнгәдер инде Сәгъдулла: «Әйдә, ясинне укы», — диде. Ясинне начар беләм, дим. Белгән кадәр укы, ди. Рядовой солдат минем белән командовать итә хәзер. Ясин сүрәсен укый башладым...

Шулвакыт бер пароход үтеп китте. Фронтка таба. Без дулкын арасында калдык. Сигнал бирер идек, кычкырырга — тавыш, атарга корал юк. Шуннан Нургали әйтә: «Малайлар, үләбез, Аллаһ безгә шулай язган», — ди. Укы, ди миңа. Миннән башка укый белүче юк... Тагын бер пароход... бу юлы яныбыздан гына узып китте. Безне күрерләр дип шулкадәр өметләндек инде, тик... күрмәделәр. Бик тә үкенечле булды. Пароходның бусы да узып киткәннән соң, көчле паника башланды. Инде күпме акканыбызны да белмибез. Тагын бер малаебыз юкка чыкты. Бөтенесе дә Дунай төбенә китеп бардылар. Алай да уннан артык калдык әле. Татарлардан берне генә югалттык. Каеш тота безне, муен тота. Баш башка тигән. Минеке Сәгъдулла белән. Болай эшләү шактый җиңеллек бирде безгә.

Менә тагын бер пароход килә. 300-400 метр ераклыкта булгандыр бездән, туктады бу. Туктады да прожектор белән Дунай өстен яктырта башлады. Көтәбез инде безгә кайчан төшәр икән дип. Йә Аллаһ, йә Аллаһ безгә төшсә иде, дибез. Миңа тагын «укы да укы» диләр. «Әлхәм»не укый башладым.



www.darul-kutub.com

Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, синнән генә ярдәм сорыйбыз дибез бит бу сүрәдә. Бөтен дөньяны яктырта. Шактый вакыт яктыртты, әмма безгә төшми. Тагын паника башланды... һәм менә, Аллаһның рәхмәте, берзаман безгә дә төште. Яктылык эчендә калдык. Яктырттылар да, яктылыкны алмыйлар, гел безнең өстә тора. Безне күргәннәрен аңлап алдык. Шатланыргамы, шатланмаскамы — белгән юк. Болар кемнәр икән, фашистлармы, венгерләрме, әллә безнекеләрме дибез. Күпмедер вакыттан соң яныбызга ике көймә йөзеп килде. Без «товарищи, товарищи» дибез. Болар «другари, другари» диләр. Югославлар икән... Соңрак без Дунайда йөз чакрым тирәсе акканыбызны белдек.

...Австралиянең башкаласы Венаны яулап алган көн — 13 апрель. 15 апрельдә совет гаскәрләре, ә алар белән бергә НКВД батальоннары да сугыша-сугыша Санкт-Пельтен — Тулын — Корнейбург линиясенә барып җитеп, анда Америка гаскәре белән очрашты. Безгә алар белән багланышка керүне катгый тыйдылар. Шул рәвешле Вена операциясе тәмамланды.

***

Мин гомерем буе кешелеклелек тәгълиматы тарату тарафдарымын. Бөек Ватан сугышы тәмамлануның 70 еллыгы якынлашкан көннәрдә дә илебезгә килгән шушы олы афәт хакында бәхәсле сүзләр, ялган-боһтаннар язучылар, сөйләүчеләр бар. Гомерләрен бәндәләр иминлегенә багышлаучыларның каһарманлыгына күләгә төшерергә тырышучылар бар. Мин аларны кискен тәнкыйтьлим: «Белегез, батырлар Ватанга хезмәт итте!»

***Нурия ӘЛМИЕВА, журналист***



www.darul-kutub.com

# ӘТИЕМ ЯДКЯРЕ

*Бөек Ватан сугышы башланганда әтием Габдерәшит Сөнгать улы Мәһдиевкә 23 яшь тулган була. Яшьтәшләре РККАга (Эшче-крестьян Кызыл Армия) каралган вакытта аны «халык дошманы» — мулла малае дип армиягә алмыйлар. Әлбәттә, моңа бик кимсенә. Хәрби хезмәткә ул сугыш башланырга нәкъ бер ай калганда чакырыла. Егетнең шатлыгы эченә сыймый. Ни дисәң дә кеше рәтеннән урын биргәннәр бит! Авыл тормышының михнәтләреннән, кыерсытудан, хаксызлыктан котылуы да җанда өмет уята. Әмма бу шатлыклар озакка түгел икән — Бөек Ватан сугышы башлана. Ул үзе белән кайгы-хәсрәт, югалтулар, зур авырлыклар алып килә. Йөрәкләре, җаннары якты хыяллар, өмет белән тулы шушы буынга язмыш биниһая зур сынаулар әзерләп куйган. Аларның иң гүзәл, иң матур яшьлек елларын «сугыш аждаһасына» йотарга язган икән...*

*Тагы кайгы-хәсрәт, югалтулар, олы михнәтләр, үлем белән яшәү арасында изалану...*

*Хуш исле канәфер, шомырт чәчәкле Җиңү көнен Дан Орденлы сапер-минер, кече сержант Рәшит Мәһдиев Чехословакия башкаласы Прагадан 60 чакрым ераклыктагы Хомутов шәһәрчегендә каршылый.*

*Халкыбыз бәяләп бетерә алмаслык корбаннар бәрабәренә фашизмны җиңүгә иреште. Заманалар үзгәрүе белән, Бөек Ватан сугышы турында, анда катнашканнарга карата да төрле фикерләр әйтелә. Әмма азатлык хакына, бәйсезлек хакына гомерләрен, яшьлекләрен корбан иткәннәр алдында без генә түгел, килер буыннар да мәңге бурычлы!*

*Сугышта күргәннәре, кичергәннәре турында әти еш сөйли иде. Кулына каләм алып хатирәләрен кәгазьгә сырлаганын да күргәләдем, әмма язганнарын туплап бастырырга ул ничектер җөрьәт итмәде. Күптән түгел аның архивын күздән*



www.darul-kutub.com

*кичергәндә сугыш турындагы истәлекләренә тап булдым һәм шуларны беркадәр эшкәртеп укучылар игътибарына тәкъдим итәм.*



## «КЫРЫК БЕРНЕҢ КЫЗУ ҖӘЕ»

Безнең бер мең ике йөз солдаттан торган эшче батальон 1941 елның май ае азакларында Казанда оештырылды. Подразделение, нигездә, шәхес культы елларында «халык дошманнары» балаларыннан тора иде. 2 июнь көнне безне тауар вагоннарына төяп көнбатышка таба алып киттеләр. Дүрт көн баргач, Көнбатыш Белоруссиядә поляк армиясенең ат абзарына кертеп тутырдылар. Алтынчы июньнән егерме икесенә чаклы, карьердан китерелгән дәү ташларны кувалда белән ваклап, бетоннан измә ясап хәрби аэродромда очу полосасы төзедек. Эш ашаган ризыгыбыз кире чыгар дәрәҗәдә авыр булды.

Сугыш башланган көнне батальонны көнчыгышка таба җәяүләп алып киттеләр. Атлый торгач, шактый ара үтелгән,



www.darul-kutub.com

Витебск-Орша арасында әрәмәлектә төн кундык. Иртәгесен, әле таң атмаган иде, батальон политругы Шаповалов безнең подразделениегә «145 нче Аерым инженер-сапер батальоны» дигән исем бирелүе турында боерык укыды һәм хәрби ант кабул иттек. Безнең төп бурычыбыз түбәндәгеләрдән гыйбарәт иде: оборонада торганда дошман кинәт үтеп кермәсен өчен чәнечкеле тимерчыбыктан киртә кую, миналар урнаштыру, гаскәрләребез чигенгәндә дошман тоткарлансын өчен юлларны миналау, күперләрне шартлату, һөҗүмгә күчкәндә су-елгалар аша күпер сугу, дошман куеп калдырган миналарны эзләп табып зарарсызландыру, пехота, танклар һәм бөтен төр техника үтү өчен шартлар булдыру. Шуңа да карамастан кулыбызга автомат яки винтовка бирергә ашыкмадылар, әллә инде ышанып бетмәделәр — һәрхәлдә сугышның беренче айларында кулдан лом, көрәк, чүкеч, балтаише эш кораллары төшмәде.

Безнең төп эш урыныбыз да нейтраль полоса иде. Бер якта дошман позицияләре, икенче якта НКВДның сак гаскәре, халыкта аны «заградотряд» дигән исемдә йөрттеләр. Уртада без мина кырлары ясыйбыз, гитлерчыларга тозак куябыз. Тылга таба чыгу катгый тыела. Шундук тотып атачаклар. Шулай бервакыт яралы солдатны озата барырга дип бер юаш кына сугышчыны җибәргәннәр иде. Медсанбатка иптәшен тапшырып частька кайтып барганда, бичара заградотрядка очрап харап булган. Командирыбыз аны эзли, егетнең кая югалганын ачыклый башлагач, югарыдагыларның берсе мәсьәләне куертмаска боерган.

Сугышның беренче айларында бик авыр мизгелләр күп булды. Аңлашылмаган чаклар да булгалады. Дошман техникасын үткәрмәс өчен аның һөҗүм итү юнәлешләрендә көрәк белән тирән котлованнар казыттылар. Эш шул чаклы авыр иде ки, ашаган ризык кире килә иде. Чокырның немец килә торган ягы сөзәк, каршы ягы туксан градуска текә. Дошман танкы шул



www.darul-kutub.com

текә ярга килеп төртелә дә туктап калачак, имеш. Әмма немец безнекеләр уйлаганча тиле түгел икән шул. Һөҗүм башланыр алдыннан фашист бомбардировщигы без атна буе газапланып казыган чокырның нәкъ уртасына бомба китереп сылый да, шартлау дулкыны белән күтәрелгән балчык, аны тигезли дә куя.

Кырык бернең июлендә батальон составында җимерүче-шартлатучылардан торган дүртенче рота сугышчылары Смоленск тирәсендә камалышта харап булды, безне, ягъни беренче, икенче һәм өченче роталарны машиналарга төяп тылга күчерергә өлгерделәр. Шулай итеп исән калынды.

## БАШКАЛА ОБОРОНАСЫ

Мәскәү янына кадәр кайтып җиттек Волоколамск юнәлешендә ныклы оборона сызыгы булдырылды. Шул көннәрдә безгә Башкомандованиенең «Бер адым да чигенмәскә!» дигән 227 нче мәгълүм боерыгы игълан ителде. Сугышның иң киеренке хәлиткеч айлары иде ул.

Берзаман безнең частькә өстәмә көчләр китерделәр. Болар сәер генә гаскәр булып чыкты. Русча бер авыз сүз белмиләр. Үзләре кыска буйлы, баштан аяк мех киемнәргә төренеп беткән, игезәкләр шикелле бер-берсенә охшаш, кысык күзле кешеләр. Яннарында хикмәтле генә чаңгылары да бар. Төньяк, Себер халыклары икән, аучылар булып чыкты алар. Хәрби хәрәкәтләрдә нинди роль уйнаганнарын белмим, алар ничек кинәт пәйда булган булса, бераздан шулай ук юкка да чыктылар.

Иң кыен, иң канкойгыч сугышлар октябрь-ноябрь айларында Мәскәү оборонасы көннәрендә булды. Хәтердә 4 октябрь вакыйгалары уелып калган. Безнең саперлар подразделениесен дошман килә торган юнәлешкә тараттылар, хәрби бурыч куелды. Иптәшләремнән Кукмара егете Иван Балякин, Әтнә районыннан Госман Ибраһимов, тагы бер иптәш (исеме истә түгел) Истра шәһәреннән Волоколамскига таба



www.darul-kutub.com

бер чакрымлык арадагы ике юлны сакладык. Бу урыннарда миналар куелды. Сменалап уникешәр сәгать сакта тордык. Хәрби задание буенча без дошман генераль һөҗүмгә күчү белән, юлларга мина урнаштырып, көйләп куярга һәм безнекеләрнең соңгы солдаты узу белән юлны ябып иң ахыргы кеше булып китәргә тиеш. Фашистлар көчле һөҗүмгә күчте. Миналарны урнаштырырга дигән боерык булды. Дошман бик якын, аларның хәтта танк моторы тавышы ишетелә иде. Танкка каршы миналарны урнаштыру үтә катлаулы һәм куркыныч эш. Сапер бер генә тапкыр ялгыша дигән әйтем бар. Запалны дөрес куймасаң, мина шундук шартларга мөмкин. Миналарны урнаштырып бетергәч Истра елгасы буйлап чигенә башладык. Бәхетебез, өлгердек тагы. Елга буендагы куаклар да саклагандыр. Дошман безне камалышка ала алмады. Елганың икенче ярына чыктык. Башкалага нибары илле чакрым калган иде. Высоково авылына җиттек. Дошман шушы авылны алгач, кич җитте һәм һөҗүм туктатылды. Шул урыннан ярты чакрымнар Мәскәүгә таба киткәч галәмәт зур бетон күпер бар иде. Безгә әлеге күперне шартлату бурычы куелды. Без төне буе шуны шартлату өчен әзерлек эшләре алып бардык, чөнки гитлерчылар гадәттә иртүк һөҗүмгә күчәләр иде. Күпергә танкка каршы миналар, як ягына куәтле шартлаткычлар куелды. Төне буе шул күпердә мәш килдек. Бик салкын кырык градуслы көннәр иде бу. Солдатларның битләре өшеп каралып беткән иде. Өстә телогрейка, аның өстеннән шинель, сырган чалбар, аякта киез итек, башта шлем астыннан киелә торган йон башлык, аның өстеннән бүрек. Иртән дошман һөҗүмгә күчү алдыннан артиллерия әзерлеге ясады. Шул чакта күперне шартлаттык һәм Волоколамскка таба бара торган юлга техника үтмәслек итеп аркылы-торкылы агачлар кисеп аудардык. Шуннан соң гына Ленино-Снегири авылына чигендек. Бу авыл безнең подразделение өчен оборона тотуның иң соңгы ноктасы иде. Бер адым да чигенерлек түгел,



www.darul-kutub.com

чөнки башкалага бик якын ара калып бара иде. Без бу хәрби бурычны искиткеч зур югалтулар бәрабәренә, намус белән үтәдек.

Алга таба китеп шуны да искәртим, әлеге авылның музеенда 1984 елда безнең 145 нче инженер-саперлар батальоны сугышчылары хөрмәтенә махсус экспозиция ачылган иде. Тантаналарда ветераннарыбыз да катнашты.

## КОНТРҺӨҖҮМ БАШЛАНДЫ

1942 елның яз, җәй айларында генерал Рокоссовский җитәкчелегендәге 16 нчы Армия контрһөҗүмгә күчте. Бу чорда подразделениенең составы бик нык сирәгәеп яңа көчләр белән тулыландырылган иде. Батальонга төрмәләрдән азат ителгән сәясәткә мөнәсәбәте булмаган статьялар буенча хөкем ителгәннәрне һәм «төрмә стажы» шактый булган уголовникларны китереп тутырдылар. Араларында курку белмәс «ташбаш» юлбасарлар да байтак иде. Алар үтеп баручы йөк машинасы әрҗәсенә сикереп менеп андагы товарны «үзләштерү»дән дә, юлда очраган крестьян хуҗалыгын «чистартып» чыгудан да тайчанмыйлар, ә инде әсирлеккә төшкән немец солдатын сугып егып аның ранецын умырып алып «әрчү» алар өчен пүчтәк бер нәрсә иде.

Командирлар арасында да төрлесе бар иде. Күбесе чын мәгънәсендә кайгыртучан, мәрхәмәтле, кешелекле, әмма араларында күрәләтә адәм баласын утка кертеп үтертә торганнары да булды. Шул уңайдан бер вакыйга истә калган: кышкы айларның берсендә туң җирдә дошман куеп калдырган миналарны эзләп зарарсызландырып йөрибез. Күптән түгел генә батальонга сафтан чыккан сугышчылар урынына яңа гаскәр килде. Алар әле тәҗрибәсез. Бездән ничек эш итәргә икәнен өйрәнеп кенә киләләр. Сапёр бер генә тапкыр ялгыша дигән мәкальне отып калдылар инде. Төп максат: минаны саклык белән генә чистартып, боз-кардан аралап, запалын борып



www.darul-kutub.com

алудан һәм аның таба зурлыгындагы корпусын алып зарарсызландырудан гыйбарәт. Минаны оясыннан чыгара алмаган очракта, аның тоткасына озын тимерчыбык бәйләп, үзебез ераккарак китеп шартлатырга мәҗбүрбез. Шулай берзаман табылган минаны чыгара алмый бимазаланып ятканда офицерларның берсе:

— Вакыт әрәм итеп, нәрсә маташасыз анда, кая әле, менә болай эшлиләр аны, дип дуамалланып, кулындагы сапёр көрәге белән «таба»га ябышкан кантарга оруы булды, бик көчле шартлаудан соң 7-8 егет җан тәслим кылды, үзенең дә әгъзаларын җыеп алып җирләдек.

Югары катлау офицерлары арасында яһүдләр күп иде. Берсе истә калган, куркак иде, бахыр. Көн актысында алгы сызыкта эшләп эт булгач, стройга тезеп, 20 чакрымга тылга тәпиләп кайтарта иде. Икенче көнне таң белән эш урынына барабыз. Югыйсә, шунда эшләгән җирдән читкәрәк алып китеп кенә ял иттерәсе. Шулай итеп бу безне тәмам интектереп коры сөяккә калдыра язды. Аны башка частькә күчергәч кенә җиңел сулап куйдык.

## АДӘМ БАЛАСЫ ЧЫДАМ ШУЛ...

1942 елның июль башларында оборона тотканда фашист бомбардировщигы безнең гаскәр торган районга һөҗүм итте. Һәлак булучылар байтак иде. Рота парторгының гүдәсен дә таба алмадык. Яныбыздагы бер таза гына егетнең (Башкортстаннан иде бугай, фамилиясе истә калмаган) сул аягы төптән үк өзелгән иде. Без аны плащ-палаткага салып күтәреп медсанбатка алып киттек. Яралы шок хәлендә берни булмагандай, безнең белән сөйләшеп бара:

— Егетләр, менә мин котылдым инде, сезнең дә шушы мәхшәрдә исән калуыгызны телим.

Ул бичара безне кайгырта бит әле. Күңелемнән аның исәнсау туган якларына кайтуын теләдем.



www.darul-kutub.com

Кеше нинди генә мохиткa эләкмәсен, гаҗәп дәрәҗәдә түземлек, сабырлыкка ия икән. Моны үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм. Снаряд шартлау, пуля яңгыры бер нәрсә, һава шартларының кырыслыгы: җиле-яңгыры булсын, чатнама суыгы-эссесе булсын адәм баласы бөтенесенә дә яраклаша, чыдый икән.

Аллаһның рәхмәте, биш ел дәверендә чирләмәдем дә, ныклап хаста да булмадым. Хәтеремдә 1943 елның гыйнвар-февраль айлары. Сталинград оборонасын тотабыз. Дала җиле үзәкләргә үтә. Өстә сырма-телогрейка, бүрек, киез итек. Ашарга кирпеч ипи өләштеләр. Аны пычак белән кисәрлек түгел — боз булып каткан. Аптырагач аркылы пычкы белән кисеп, бүләбез дә кайнар суга салып җебетеп, ашыйбыз. Төн кичергә кирәк. Ачык кырда сиңа бирәү дә урын-җир түшәп куймаган. Кар көртен казып, плащ-палатка җәеп, шуңа сузылдык, өскә шулай ук плащ-палатка яптык. Төнлә безне кар каплап киткән. Иртән кар астыннан көчкә табып казып алганнар. Ничекләр исән калганбыз: колак ишетә, гәүдә үзе юк шикеллерәк — җылысы беткән. Өстерәп чыгардылар. Карда әвәли торгач, җан керде тагы. Шунысы гаҗәп ник беребез төчкерсен!

Йокы мәсьәләсе дә гаять мөһим. Кайвакыт ару-талу шул дәрәҗәгә җитә иде ки организм ихтыярга буйсынмый башлый. Марш-бросок вакытында сафта барган шәпкә күзләр йомылып, йоклап киткән һәм нәкъ шул мизгелдә төш күргән чаклар да булды.

Ашау мәсьәләсенә килгәндә, сугышның башлангыч чорында кыенлыклар байтак булды. Кыр кухнясына снаряд эләгеп ач калган чаклар да булгалады. Андый чакта һәркем үзен кайгыртты. Бервакыт Сталинград фронтында блиндаж янында ниндидер эре терлек ятканына игътибар иттем. Снаряд тиеп үтергәндер инде. Кардан чистартып, итен кисеп алып котелогыма кар эретеп салып, учакка астым. Пешереп кабып кара-



www.darul-kutub.com

сам, телеңне йотарлык. Байтак еллар узгач кына белдем дөя ите булган икән.

Дошманны үз өнендә тукмый башлагач, ашау тагы да төрләнде. Ротаның аш пешерүчесе эшсез калды диярлек. Нәрсә әзерлим, дип тора. Чөнки немец ташлап киткән утарлардагы булган бөтен кош-корт, мал-туар, азык-төлек запасы безнеке. Кем нәрсә таба шуны үзе әзерләп яки пешерергә заказ биреп әзерләтә. Алпавытның хәзинәдә булган бөтен җиһазына, утарына да без хуҗа. Ашап-эчкәч тәрәзәне ачып өстәлдәге эскәтерне генә селкибез. Савыт-саба юып ятып булмый бит инде. Шул рәвештә атна-ун көн яшәп без утардан китеп барганда да савыт-саба кимемәгән була иде.

## БЕХИ АВЫЛЫ ИСТӘЛЕГЕ

...Украина. Коростень районы, Житомир өлкәсендә оборонада ятабыз. 1943 елның октябрь ае бу. Бер ай элек дошманның көчле басымы белән Бехи авылын калдырып көньякка таба чигенгән идек. Авыл янындагы үзәнлектә фашистларның һөҗүм юнәлешендә без ясаган мина кыры. Күп итеп ЯМ-5 (ящиклы мина, авырлыгы 5 кило) куелды. Шул кырны саклыйбыз. Ай азакларында дошман гаскәре хәрәкәткә килде. Ерхов һәм Братусь исемле ике хезмәттәшем белән миңа мина кыры аша соңгы солдатны уздырып, сукмакны бикләү бурычы куелды. Бер яралы солдаттан «тагы безнекеләр бармы анда» дип сорап, ул «миннән соң башка кеше күренми» дигәч, юлны бикли башладык. Ерхов, ул Рязань кешесе иде:

— Иптәш ефрейтор, инде дошман танкларының тавышы ишетелә, харап булабыз бит, тизрәк сызыйк моннан, — дип кыбырсый башлады.

— Танкка каршы гранаталар нәрсәгә соң? Хәрби бурычны үтәргә кирәк бит, — дип җавап бирдем.

Миналар куеп бетереп взвод командиры лейтенант Борис Буслаевка кайтып заданиенең үтәлүе турында әйттек.



www.darul-kutub.com

27 декабрьдә Буслаевны штабка чакырып алдылар. Ул бераздан әйләнеп килде һәм безгә сугышчан заданиене җиткерде. Отделение командиры сержант Чайкинга ике отделение сугышчылары белән дошман оборонасында безнекеләр узып китү өчен юл ачарга: миналарны зарарсызландырырга, чәнечкеле тимерчыбыклардан ясалган чикләрне юк итәргә дигән бурыч куйды. Гадәттә мондый хәтер боерык булуга, илле яшьлек Чайкинның һушы китә иде. Взвод командиры иптәшебезнең әлеге «сыйфаты»н чамалый. Ахыр чиктә хәрби бурычны үтәү отделение командиры урынбасары буларак минем өскә төшә. Мина эзләү җайланмасы, компас, эш кораллары күтәреп киттек заданиене үтәргә. Иң мөһиме, көн яктыра башлаганчы эшне тәмамларга кирәк.

Тиз арада эшне башкардык һәм боерыкның үтәлүе турында хәбәр иттем. 28 декабрьдә 6 сәгатьтә дошманның котын алу өчен артиллерия әзерлеге башланды. Канонада шул дәрәҗәдә көчле булды, хәтта янәшә сөйләшеп торучыны ишетерлек түгел иде. Шуннан соң взвод командиры Борис Буслаев, Мусин Бату һәм мин һөҗүм буласы урынга юнәлдек. Пехота, нигездә, дошманнан яңа гына азат ителгән җирле халыктан иде. Атакага күтәрелергә дигән әмер булуга болар окоптан чыкты да сузылып ятты. Һөҗүмгә күтәрелергә исәпләре юк. Тыннары да чыкмый. Каршыдагы дошманның ут ноктасы безгә баш күтәрергә дә ирек бирми.

— Нигә җавап уты ачмыйсыз? Пулемётларыгыз бар ич, станковыйдан бәреп тончыктырырга була бит! — дип команда бирәбез.

Дәшмиләр. Барып затворны ачып карасак, ай буе чистартылмаган да, майланмаган да шуңа да эшкә ярарлык түгел икән.

Ул арада артиллерия дивизионының расчеты килеп җитте. Алар танкка каршы ата торган туп китереп, фашистларның ут ноктасына бер-ике залп ясады. Пулемёт тынды. Шул миз-



www.darul-kutub.com

гелдә атакага күтәрелеп фашистларның оборона сызыгына ябырылдык. Окопта бер немец солдаты үлеп ята, блиндаждан 9 фашист кулларын күтәреп килеп чыкты. Аларны коралсызландырып өлкән сержант Волк җитәкчелегендәге бер төркем солдат тылга алып китте. Буслаев, Мусин һәм мин дошманның чигенүче төркемен эзәрлекләп киттек. Бу төркемдә утызлап солдат яннарында бер офицер да бар. Солдатлар яңа гына әсирлеккә төшкән хезмәттәшләренә карата нинди җәза кулланылыр икән дип күзәтә. Үзләре дә кул күтәрергә дип икеләнеп тора болар, ут ачмыйлар. Без дә атуны туктаттык. Тегеләрнең офицерлары тузына бит, бик каты итеп кычкыра. Безнең исәп — авыл очындагы йортны әйләнеп үтеп, дошманнарның каршысына кинәт кенә килеп чыгу һәм төркеме белән кулга алу. Шул мизгелдә взвод командиры Буслаев яраланды. Снайпер пулясы аягына эләкте. Мусин Бату аны култыклап тылга алып китте.

Соңыннан билгеле булды, ул көнне фронт 60-70 чакрымга көнбатышка таба киткән икән. Бу зур уңыш иде.

Ровно шәһәрен азат иткәч, бер кичне безне бөтенебезне дә клубка җыйдылар. 7 нче штурмлы инженер-саперлар бригадасы командиры, полковник Бараш исемлек буенча сәхнәгә чакырып операцияне уңышлы башкарып чыккан өчен хөкүмәт бүләкләре өләште. Взвод командиры Буслаевка «Бөек Ватан сугышы» Ордены, Федор Волк, Бату Мусин һәм миңа солдат өчен иң югары билге булып саналган «Өченче дәрәҗә Дан» Орденнары тапшырды.

## ҮЛЕМ БЕЛӘН ЙӨЗГӘ-ЙӨЗ

Язмыштан узмыш юк, диләр. Адәм баласы өчен иң зур сынау яу кырында икән ул. 1418 көн дәвам иткән кан коешта ничәмә-ничә кеше шәһит булганын әле дә булса исәпләп чыгара алмыйлар. Төп-төгәл итеп аны исәпләрлек тә түгелдер. Җиде урынлы саннар фаразлана. Ә бит аларның



www.darul-kutub.com

һәркайсы кемнеңдер газизе иде. Күпме өмет өзелгән, күпме нәсел киселгән, күпме бала ятим калган! Кешелек җәмгыятенә, яшәешкә сугыш алып килгән коточкыч фаҗиганең асылы да нәкъ менә шундадыр. Сугышка кергәндә мин шушы мәхшәрдә исән калырмын, туган илемә кайтырмын дип һич кенә дә башыма китермәдем, хәер, бу хакта кем дә уйламагандыр. Ходайның рәхмәте, биш ел ут эчендә йөреп ник бер зыян-зәүрәт күрим! Ә шулай да Газраил фәрештәнең канат очлары кагылып киткән мизгелләр булды. Менә шуларның берничәсе.

Бервакыт кичкырын взвод белән блиндажда кунарга җыендык. Берәүләр йоклау өчен урын әзерли. Үзем гадәттәгечә өс-башны тәртипкә китерәм, гимнастеркага төймә тегеп утыра идем. Каршымда бер иптәшем пистолетын чистартып, майлап утыра. Кинәт пистолет үзеннән үзе атып җибәрде. Нәкъ чигәм турысыннан пуля сызгырып узды. Эсселе-суыклы булып киттем. Дусларым да сикергәләп куйды.

Икенче вакыйга болай булды: төн кичерү өчен безнең взвод авыл өенә кереп тулды. Мин чиратым җитеп тышкы яктан постка бастым. Берзаман йомышлап килергә дип куак арасына кереп китүем булды, шуны гына көткәндәй, берәү атылып йортка кереп тә китте. Мин аваз салырга да өлгерми калдым. Өй эчендә тавыш-гауга купты.

— Башыгызны югалттыгызмы әллә? Дошман кереп кырып чыга бит барыгызны да! Кем сакта иде? Китерегез монда! — дип җикеренеп, кобурасыннан алтатарын чыгарып миңа ташланды. Үзем дә авыз ачып тормас идем. Үзем хәл итәргә әзер идем. Бары тик фронтташ дуслар арага кереп «кызу канлы» иптәшне аралап калдылар.

Өченче бер вакыйга болай булды: машиналарга төяп, колоннасы белән фронтның икенче урынына күчерәләр. Бервакыт приваля ясадык. Егетләр каяндыр канистра белән эчемлек юнәткәннәр. Кайберләре кәефләнеп тә алган. Миңа



www.darul-kutub.com

да өлеш бар икән. Фляжкамның капкачына «зәм-зәм суы»н тамызыйм дип торганда өлкән офицер килә дигән хәбәр ишетелде. Мәҗлесне түгәрәкләргә мәҗбүр булдык. Шул вакытта «По машинам!» дигән команда булды һәм бәхетемә теге эчемлекне татымый калдым. Кичкә таба аяныч хәбәр таралды. Мәҗлес корып эчемлекне авыз иткәннәр бөтенесе дә агуланып җан тәслим кылган.

1943 елда Сталинград сугышлары тәмамлангач, безнең подразделениены сугыш кырларын шартламый калган снарядлардан, миналардан арындырырга калдырдылар. Апрель ае иде. Миңа хәрби задание итеп пакет белән донесение тоттырдылар да шактый еракта урнашкан штабка илтеп тапшырырга куштылар. Яндагы тимер юл разъездына чыгып тауар поездының ачык платформасына кереп постым. Хәйран еракларга киткәч сикереп төшеп калдым. Карта, компас буенча юнәлешне чамалап карлар ерып китеп бардым. Ул вакытта «тавык күзе» чире йоккан иде. Организмда витаминнар җитмәүдән яз көне була торган зәхмәт, караңгы төшә башлагач күзләр сукырая. Кая барганыңны да күрмисең.

Телеграф баганаларындагы сузылган чыбыкның зыңлаган тавышы буенча шактый ара үткәч, язгы сулар шау итеп торган елга ярына җиттем. Бер колга табып шуның белән елга төбен капшап көчле агымлы суга кереп киттем, Аллаһка тапшырып. Берзаман тирән чоңгылга эләгеп көч-хәл белән йөзеп чыктым. Ярга чыгып биштәремдәге тротил шашканы ягып киемнәрне киптереп алдым. Янә киенеп тагы алга таба атладым. Яңадан елга шавы ишетелде, аны да ерып чыктым. Шул рәвешчә шактый баргач караңгы төшә башлады. Суытып җибәрде. Салкын җилдән саклану өчен бер фанера кисәге табып шуны телеграф баганасына сөяп аркамны терәдем. Җылыну нияте белән чыбык-чабык, кипкән әрем җыеп учак ягып карыйм. Зур өем коры чыбык күкерт урынына күз ачып



www.darul-kutub.com

йомганчы яна да бетә. Төне буе шулай бимазаланып чыктым һәм хәлдән таеп егылдым. Таң алдыннан гына изрәп йокыга талганмын. Кояш күтәрелеп, җылытып кыздыра башлагач уянып китсәм, күктә бер таныш кош сайраган тавыш. Тургайлар сайрый икән. Компас-карталар буенча юнәлешләрне барлагач юлны дәвам иттем. Дала өсте ниндидер ялтыравыклы утлар белән бизәлгән. Шуның якындагысына барып карасам камалышта калган фашистларга кыш көне самолётлардан ташлап калдырылган әрҗәләр икән. Алар җиргә төшкән шәпкә ярылганнар да консерв банкалары таралып кояш нурларында ялтырап ята. Кар эчендә әйбәт кенә сакланган ризыклар иде ул. Тамакны ялгап алдым һәм биштәремә дә тутырдым. Ниһаять, тиешле пунктка барып җитеп пакетны тапшырдым һәм үзебезгә кайтып киттем.

## МАРШАЛ РОКОССОВСКИЙ

Белоруссиянең калын урманнары. Безнең подразделение юан-юан наратларны аударып, бурап бер тәүлектә йорт салабыз. Эш авыр. Чи бүрәнәләр адәм күтәргесез. Фронт командующие өчен урман куелыгында яшерен ставка төзибез. Бервакыт эшләп ятканда затлы хром пальто, каракүл бүрек кигән берәү пәйда булды. Бу генерал Константин Рокоссовский иде. Ул читтәнрәк безнең эшләгәнне күзәтте. Тәмәке кабызды. Байтак вакытлар карап торды.

Шушы минутларда нәрсәләр турында уйлады икән ул? Үзенең михнәтле язмышы, гаиләсе һәм якыннары турындамы, әллә инде бөек «юлбашчы» тарафыннан репрессиягә эләгүе хакындамы, әллә 1939-1940 елларда НКВД гаскәрләренең полякларның меңәрләгән асыл ир-егетләреннән торган хәрби частьләрен кырып бетерүе турындамы, яки шушы сазлыклы урманда авыр эш башкаручы, үзенеке кебек ачы язмышлы йөзәрләгән хокуксыз бәндәнең киләчәге турында уйлады микән, ул кадәресе мәгълүм түгел иде.



www.darul-kutub.com

Форсаттан файдаланып, күренекле хәрби эшлеклеләрнең берсе генерал һәм соңрак маршал дәрәҗәсенә чаклы җиткән полководец Константин Константинович Рокоссовский (1896-1968) турында мәгълүмат биреп узу да урынлы булыр. Ул поляк милләтеннән. Яшьлектән үк язмышын армия белән бәйләгән. Кече унтер-офицер сыйфатында Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Кызыл Гвардиядә 1917 елның октябреннән. Ватандашлар сугышында кавалерия эскадроны һәм полк командиры була. Соңрак кавалерия полкы, бригада, дивизия белән командалык итә, ә 1936 елдан корпус командиры була. Большевикларның эшче-крестьян армиясен төзегәндә патша армиясе офицерларын башта үз итеп, ә соңрак читләштереп хәтта эшләрендә гаеп табып, зинданнарга ябулары сер түгел. Ә шәхес культы елларында әлеге затларны кулга алып, ГУЛАГларга озату гадәти күренеш саналган. Репрессияләр тегермәне Кызыл Армиянең иң югары башлыкларыннан алып полк командирларына чаклы «тарттырганлыгы» мәгълүм. Псков гарнизоны башлыгы, 5 нче кавалерия корпусы командиры Константин Рокоссовскийның кулга алынуы да гайре табигый булмаган. Сорау алганда җәзалаулар, шәхесне кимсетүдә гестапочылардан ким кыланмаган палачлар кулыннан котылып, сынмый-сыгылмый, хезмәттәшләреннән беркемне дә сатмый, нахак гаепләү кәгазьләренә кул куймый, тулысынча акланып, Ленинградның мәшһүр «Кресты» төрмәсеннән иреккә чыккан генералга теш табибы сукмагын шактый таптарга туры килә. Сугыштан соң байтак вакыт узгач та Константин Константинович янында һәрвакыт пистолет йөрткән, моны күргән кызы нигә болай эшләвен сорагач, маршал:

— Янәдән кулга алырга килсәләр, тере килеш бирелмәячәкмен! — дип кырт кискән, имеш.

Бу җаваптан «корыч бабай» егетләренең ни дәрәҗәдә оста эшләүләрен чамаларга мөмкин.



www.darul-kutub.com

Маршалның оныгы подполковник Константин Рокоссовский истәлекләрендә бер вакыйга баян итеlә. Фронт командующие бердәнбер кызы, 17 яшьлек Аделаиданың радист булып сугышка китүенә күңеленнән никадәр риза булмаса да, баласы инәлеп сорагач, рөхсәт бирергә мәҗбүр була. Көннәрдән бер көнне кыз әтисе янына алгы сызыкка килеп чыга. Шул чакта дошман самолётлары кинәт пәйда булып, бомба яудыра башлый. Халык кайсы кая тарала. Әти кеше гәүдәсе белән баласын каплый. Һава һөҗүме тәмамлангач утырып килгән машиналарының күккә очуын күреп өнсез калалар. Аделаида ханым гомере буе бу хакта тетрәнеп сөйләгән икән.

К.Рокоссовский тарихи вакыйга — Җиңү парады белән командалык иткән һәм Маршал Георгий Жуковка рапорт биргән кеше.

1949 елдан Польшаның милли оборонасы министры һәм ПХР Министрлар Советы рәисенең урынбасары була. 1956 елдан СССР оборона министры урынбасары булып хезмәт итә. Ике тапкыр Советлар Союзы Герое, илнең иң югары хәрби билгесе «Җиңү» ордены белән бүләкләнә. Шуны да ассызыкларга кирәк, нинди зур дәрәҗәләргә ирешкән олы җитәкче булмасын, Константин Константинович үтә тыйнак, сабыр холыклы һәм гадел кеше булып калган. Аның яраткан шөгыльләре — ауга йөрү, бакчачылык һәм печән чабу булган.

## БАТАЛЬОННЫҢ СУГЫШЧАН ЮЛЫ

Июнь, 1941ел — апрель, 1942 ел Мәскәү оборонасы. Мәскәү өлкәсе, Истра районы, Снегири авылы. Үзәк фронт составында Армия генералы К.К.Рокоссовский командалыгында сугышта катнашу.

Июль-август, 1943 ел Орел-Курск дугасындагы тарихи бәрелеш.

Поныри-Ольхватка торак пунктлары тирәсендә хәрби хәрәкәтләр.



www.darul-kutub.com

Ноябрь, 1942 ел — февраль, 1943 ел Генерал В.И.Чуйков командалыгында 62 нче армия составында Абганерово станциясе тирәсендә хәрби бәрелешләр.

Май, 1943 ел Сталинград өлкәсен миналардан чистарту.

1943 елның сентябрь-декабрь айлары Новгород–Северский һәм Коростень шәһәрләрен азат итү.

1944 елның гыйнвар-март айларында Сарны, Луцк, Ровно, Здолбунов һәм Дубно шәһәрләрен азат итү.

Июль Львов юнәлешендә немец оборонасын өзү. Владимир — Волынск, Рава-Русская, Рославль шәһәрләрен азат итү.

Август 1944 ел Сандомир шәһәрен азат итү.

1945 елның гыйнваренда Сандомир шәһәренең көнбатышында немец оборонасын өзү һәм Петракув шәһәрен азат итү.

Февральдә Одер елгасын кичү һәм Шпротау, Кельце, Зорау шәһәрләрен азат итү.

Апрельдә Нейсе һәм Шпрее елгаларын кичеп, немец оборонасын өзү, Эльба елгасына һәм Берлинга барып җитү, Виттенберг шәһәрен азат итү. Бу көннәрдә батальон сугышчылары союздаш армия — АКШ гаскәрләре белән очраша. Американнарның ачык машиналарга төялеп кара күзлек, фотоаппаратлар асып туристик сәяхәтчеләр кебек иркенләп йөргәннәрен күреп шаккаткан идек.

Май аенда Берлинның көньяк-көнбатышында дошман группировкасын тар-мар итү.

Җиңү бәйрәмен батальон Чехославакия башкаласы Прагадан 60 чакрым көньяктарак Хомутов шәһәрендә каршы алды.

Бу вакытта без 13 армия составында 19 нчы Кызыл байраклы Кутузов һәм Богдан Хмельницкий Орденлы инженер сапер бригадасында хезмәт итә идек инде. Соңыннан мәгълүм булды: Казаннан чыгып киткән 1200 кешенең ун проценты гына әйләнеп кайту бәхетенә ирешкән.

Үзем белән сугышта катнашкан кайбер фронтташ дусларымның, милләттәшләремнең исемнәрен искә алып китүне



www.darul-kutub.com

изге бурычым дип саныйм: Яруллин Хасип, Баһманов Сәлимгәрәй, Мидхәт Подмарев, Госман Ибраһимов, Әсәт Хәйретдинов, Фоат Ибраһимов, Ф. Гыйлемханов, г. Шәяхмәтов, Гаделша Сабиров, Бату Мусин, Сәетша Тимершин, Фатыйх Фәттахов.

Бүген аларның байтагы гүр ияләре инде. Урыннары оҗмахта булсын!

## ТУГАН ИЛГӘ КАЙТУ

Сугыш бетүгә безне хәрби хезмәттән азат итмәделәр. Бер еллап Украинаның Житомир шәһәрендә хезмәт иттек. Бу чорда частьтән өлкәнрәк яшьтәге фронтовиклар тәртип белән өйләренә кайта башлады, ә алар урынына яшьләр килә иде. Алмаш килеп хәрби тормышка күнегеп, бездән тәҗрибә туплагач кына туган якларга кайтырга әмер була иде. Аңа чаклы хәрби өйрәнүләрдә катнашып, көндәлек солдат хезмәтен үтәп, һич кыенсынмый хезмәт иттек. Шулай беркөн строй белән өйрәнүләрдән кайтып бара идек. Рота командиры капитан Я.Биберман подразделение белән идарә итүне миңа тапшырды. Бу чакта мин инде кече сержант званиесендә идем. Офицер юлдан читтәнрәк атлый. Мин гадәтләнгәнчә җырларга боерык бирдем. Солдатларның бер өлеше җырны күтәреп алды, ләкин яңарак алмашка килгәннәр авызларына су капкандай ләм-мим. Арыганнардыр да инде. Өстәвенә сансызлык та бар бит әле. Мин кабат:

— Запевай! — дип команда бирәм.

Санга сукмыйлар. Минем дә моңа хәтер калды. Әлбәттә, рота командиры да бу хәл белән килешә алмагандыр. Ничек инде ярты Европаны түше белән шуышып узган фронтовикларның сүзләрен сары томшыклы малай-шалай колакка да элмәсен ди. Капитан казарма ишеге төбенә килеп җитүгә солдатларны стройга тезде дә җырга кушылган егетләр белән миңа кереп китәргә боерды, ә сансызларны бүлеп алып:



www.darul-kutub.com

— Әменә бу иптәшләр белән үзем бераз шөгыльләнәчәкмен, дип алып калды.

Байтак вакыт узып, без ашап, ял итеп туйгач кына тегеләр мышнап, тирләп-пешеп кайтып егылдылар.

Шулай була ул өлкәннәр сүзен санга сукмасаң, дип уйлап куйдым... Ачу-үпкәнең әсәре дә юк, чөнки командир егетләрдән бер адым калмый үзе дә үрнәк күрсәтеп «кросс»та катнашкан.

1946 елның май ае азакларында, ниһаять, өйләребезгә кайту чираты безгә дә җитте. Тиешле кәгазьләр җыелды, боерык кулда, зарыгып көткән туганнар белән күрешү бәхете көтә. Безне әлеге дә баягы тауар вагоннарына төяп тантаналы төстә озатып җибәрделәр. Эшелон Рязаньга килеп җиткәч, без берничә якташ перронда төшеп калдык.

— Егетләр, нигә әле без Мәскәүгә, халык кайнап торган вокзалда авыр биштәр чемоданнар күтәреп тинтерәп йөрергә тиеш, әйдәгез, минем арттан. «Әйләнмәле булса да юл яхшы» дигәндәй Горький шәһәренә баручы поездга кереп кысылдык. Ул безне Люберцыга китереп бушатты. Анда шәһәр яны поездына утырып, Муромга җиттек. Вокзал дигәннәре бер кечкенә генә алачык иде. Халык шыгырым. Касса төбенә үтәрлек түгел, каплап алганнар, этеш-төртеш. Билетлар алу мөмкинлеге чамалы. Аны да состав килгәч кенә сата башлыйлар икән. «Мәскәү-Новосибирск» поезды килеп туктауга, халык вагоннарга ташланды. Кайбер җитезрәкләре хәтта вагон түбәсенә үк менеп кунакладылар. Без аптырагач ике вагон арасындагы мәйданчыкка урнаштык. Вагон ишегенә фанер чемоданымны терәтеп куйдым да аркамны сөядем. Поезд ыжгырып алга чаба. Җил сызгыра. Бераздан пижамалы таза-таза ирләр тегендә-монда йөри башлады. Янәшәдә генә вагон-ресторан икән. Урынымнан кузгалып аларга ишек ачып торырга мәҗбүрмен. Шул рәвешчә шактый баргач, сабырлыгым төкәнде. Проводникны чакырту өчен вагон



www.darul-kutub.com

ишеген каплаган фанераны кага-кага чыра иттем. Шулвакыт тәмәке көйрәтергә чыккан ирләрнең берсе проводник түтәйне чакырды. Ишекне ачуга эчкә бәреп кердек тә, апайны бөтереп алдык:

— Җиңүчеләрне вагонга кертми интектерәсең, бераздан төн җитә, шунда йокы аралаш тәгәрмәч астына төшеп үлсәк, син генә гаепле буласың, хәзер үзеңне шунда тотып тондырам, дип тузгыгач, юлдашларым мине тынычландырырга ашыкты:

— Берүк тавыш чыгара күрмә, безне харап итәсең!

Ул бичараларның әсирлектән кайтып килешләре икән…

Ханым елый-елый безне үзенең купесына урнаштырырга мәҗбүр булды. Багажымны өске шүрлеккә куйдым да юыну бүлмәсенә киттем. Көзгегә күз салсам, өс-башым забойдан чыккан шахтерныкы кебек корымга буялып беткән. Юынып, кыяфәтемне тәртипкә китергәч, өскә менеп сузылдым. Берзаман йокы аралаш ишетеп ятам, купега контролерлар кереп билет тикшереп йөри икән. Проводник хатын миңа таба ымлап:

— Зинһар, теге явызны уята күрмәгез, — дип тикшерүчеләрне юмалап озатты.

Казан вокзалында юлдашларым:

— Якташ, синең белән рәхәтләнеп кайткан идек, алга таба нишләрбез инде, — дип хушлаштылар.

1946 елның 3 июне иде бу. Бу көн хәтеремдә калган, чөнки шушы көндә «бөтенсоюз старостасы», СССР Югары Советы Президиумы Рәисе Михаил Калинин вафат булды, дип хәбәр ителде радиодан.

***

Бу урында әтинең язмалары өзелә. Сугыш турында истәлекләре белән әти даими уртаклаша иде. Өстәл янына утырып хатирәләрен кәгазьгә төшерүен дә күргәнем булды.



www.darul-kutub.com

Бүленеп-бүленеп булса да язгалаганы хәтеремдә, әмма ул ни өчендер истәлекләрен туплап бастырырга ашыкмады.

Бәхетемә заманында үземә дә әтиемнең фронтташ дусларының кайберләре белән очрашып танышырга насыйп булды. Кайсын гына алма, саф күңелле затлар, гаярь кешеләр иде алар. Сугыш михнәтләре, югалтулар аларның бәгырьләренә үтеп кереп катылатмаган, холыкларын тискәре якка үзгәртмәгән, ә бәлки киресенчә йомшарткан, сабырлыкларын арттырган гына. Җиңү бәйрәме уңаеннан очрашуларында да булдым. Мәскәү оборонасында торган җирләрдә, Ровно шәһәренә дә әтине озата бардым. Очрашуларның эчкерсезлеге истә калган. Чал чәчле фронтовикларның йөзләре шат, күңелләре күтәренке иде бу вакытта.

Әти сугыш турында сөйләгәндә, гадәтенчә, сүзнең түмен белеп хатирәләр диңгезенә чума иде. Шунысы гаҗәп, вакыйгалар моннан биш-алты дистә еллар элек узса да, көне-сәгате, вакыйга булган шәһәр-авыл исемнәрен яхшы хәтерли һәм үзен сабыр, тыныч тота иде. Фәкать ике очракта гына хискә бирелгәнен хәтерлим. Бервакыт туганнар мәҗлесендә ул сугышның беренче айларда авылларны калдырып көнчыгышка таба чигенүләре турында сөйләде. Бер юлы җимерек өйләр, морҗалары гына утырып калган йортлар, хәрабәләр арасында басып торган һәм снаряд тиеп җәрәхәтләнгән ат, аның эленеп калган эчке әгъзалары турында хатирәләре белән уртаклашканда һәм шушы үзәк өзгеч күренеш турында сөйләгәндә, авыл тормышына, атларга мөкиббән зат буларак, аның күңеле нечкәреп, тавышы калтыранып алганы сизелде. Икенче вакыйга болайрак исемдә калган: һөҗүмгә күчәр алдыннан сугышчыларга артык әйберләрдән арынырга боерганнар. Стройга тезеп коралларын, кием-салымнарын тикшергәндә бер өлкән яшьтәге солдатның биштәреннән бала киемнәре килеп чыккан. Мескеннең гаиләсе ишле икән, ата кеше туган нигезендә калган берсеннән-берсе



www.darul-kutub.com

нәни балаларына үткән-барганда кием-салым хәстәрен дә күргән икән.

Әтинең фронтташ дусларыннан исәннәрдән бүгенге көндә Әгерҗедә яшәүче миңа билгелесе бердәнбер Серафим Агафонов. Мин аның белән элемтәдә торам. Телефоннан аралашып, бәйрәмнәрдә котлау открыткалары, хатлар алышып яшибез. Серафим агайның язмышы үзе бер китап язарлык. Хәер, аның буын кешеләренең тормышлары турында да сөйләп бетергесез. Аның атасы Николай зур дәрәҗәле рухани булган. Репрессияләнгән. Серафим агай тугызынчы дистә белән барса да таза бәдәнле, киң җилкәле, күкрәк хәтле сакаллы. Аны Әгерҗедә белмәгән кеше юктыр. Киленнәре, балалары, оныклары белән матур гына гомер кичерә.

***Рөстәм МӘҺДИЕВ, журналист***



www.darul-kutub.com

# В БОМБОЛЮК С МОЛИТВОЙ

Гафиев Фасыйх 18-летним юношей в сентябре 1941 г. ушел на войну добровольцем. Он попал в десантные войска, и его отправили в город Марианталь Саратовской области, оттуда на шестимесячные курсы в военно-воздушное училище в Москву. Во время учебы в училище в самые трудные дни декабря 1941 г. он, как и все курсанты, принимал участие в обороне Москвы. После того, как враг был отброшен на 30 км от Москвы, они продолжили обучение. Через 6 месяцев Фасыйх стал стрелком-радистом, и его определили в гвардейский авиаполк, расположенный на аэродроме в Тушино.

Далее он принимал участие в освобождении Элисты, был ранен, и после госпиталя его вновь отправился в Москву, в 7-й военный воздушный корпус. По ходу войны Гафиев участвовал в окружении Сталинграда, в освобождении Ростова. Под Ростовом пытались отбить мост имени Муссолини, построенный фашистами, но, к сожалению, те успели его взорвать. Далее он участвовал в боях в Запорожье. При форсировании Днепра самолёт, на котором летел и Фасыйх для десантирования на тот берег и подготовки плацдарма для форсирования, попал под кинжальный огонь. Самолёт был вынужден повернуть обратно, а десантники, опасаясь, что самолёт не дотянет, начали выпрыгивать из самолёта. Раненный при обстреле самолёта Гафиев и еще два десантника выпрыгнули и вновь оказались обстрелянными. В Фасыйха, летящего с парашютом, снова попали. Он приземлился в нейтральной зоне — между своими и немцами. Упав в воронку, пролежал там с 4 до 8 утра с 11 ранениями, несколько из которых были тяжелыми: разбиты оба бедра, раздроблены три ребра. За эти четыре часа немцы два раза поднимались в контратаку и были в нескольких шагах от него. Истекая кровью, он лежал, ожидая смерти. Но Фасыйху повезло: один старик из трофейной команды подобрал его и



www.darul-kutub.com

оказал первую помощь. Конечно, Фасыйх будучи парнем верующим, в такие минуты не мог не вспоминать Аллаха. Да и не только в такие минуты. «Я любил прыгать с бомболюка. И всегда, когда прыгал с самолёта, молился. Бывало, садимся в самолёт, и мои боевые товарищи говорят: вон Гафиев начал бормотать», — рассказывает Фасыйх-хазрат.

«Был случай, когда под Батайском налетели немецкие самолёты и начали бомбить, — продолжает свой рассказ мухтасиб. — Я прыгнул в «стояк-ячейку»*. На меня прыгнул еще один человек, а затем еще один. Пришлось присесть. Когда бомбят, земля начинает ходить ходуном. Я начал вслух повторять: «Ля иляха илля Аллах». Майор, который был надо мной, тоже стал повторять «Господи помилуй, господи помилуй» и креститься. А третий оказался подполковником, после того как бомбежка кончилась, говорит ему: «Ну, ты даешь майор!». А тот ему в ответ, показывая на меня: «Вон, тот тоже по-своему что-то причитал».

Где война, там и смерть, а там, где смерть, там люди чаще вспоминают своего Творца. Не зря в одном из хадисов говорится о том, что смерть — лучший проповедник. Так что и офицеры, которые практически все были коммунистами, перед лицом смерти внимали ее проповеди, забывая о том, что коммунист должен быть атеистом. Конечно, можно спорить о цене такой веры, но, во всяком случае, не нам об этом судить. Сегодня Фасыйх-хазрат уверен, что все, погибшие на войне, обладающие иманом, являются шахидами. Сегодня он часто задает себе вопрос «Зачем нужна была эта война?» и не может найти ответа.

***

Послевоенная биография Фасыйха Гафиева ничем особенно не отличается от биографий миллионов ветеранов. Буду-



www.darul-kutub.com

чи по образованию бухгалтером и обладая организаторскими способностями, он занимал руководящие должности в хозяйствах района. Конечно, в советское время соблюдать религиозные правила было очень сложно, особенно если ты находишься хотя и на маленькой, но руководящей работе.

В те времена люди для совместного намаза собирались в частных домах почти что тайно. В один из таких домов и привел однажды Фасыйх абыя его шурин. Поскольку у него был красивый голос, его выбрали муэдзином. А потом, когда предыдущий имам покинул этот мир, его выбрали муллой. В 1993 г. на районном совещании имамов Гафиева выбрали мухтасибом.

Ранее он эту должность исполнял, будучи имамом мечети в родной Нижней Каменке. Однако преклонный возраст сделал затруднительным исполнение обязанностей имама. Но его организаторские способности и мудрость до сих пор востребованы. Сам Фасыйх-хазрат не раз уже просил освободить его от должности мухтасиба и переизбрать вместо себя кого-нибудь моложе. Однако ни имамы, ни руководство района не хотят видеть никого другого на этой должности, кроме Фасыйха-хазрата. «Тяжеловато, конечно, но отказываться не приходится, раз надо, значит надо», — говорит хазрат.

В 1993 г., когда он только был избран имамом мухтасибом, в Черемшанском районе было 8 приходов, сейчас в районе около 20 мечетей и, соответственно, приходов. И курировать их не так-то легко — каких только людей нет среди прихожан. Ныне в районе на Курбан-байрам режут около 700 овец и несколько коров.

Как представителя старшего поколения, Фасыйх-хазрата волнует, что среди сельских мулл мало молодых имамов, имеющих духовное образование. На сегодня в районе их только двое — в селе Лашманка и в родной деревне хазрата — Нижней Каменке.



www.darul-kutub.com

В республике Фасыйх-хазрат знаменит тем, что самым первым из всех мухтасибов вышел с инициативой сбора у населения гошра (особого вида закята) и добился успеха в этом начинании. Впервые эту инициативу он воплотил в жизнь в своей родной Нижней Каменке. В прошлом году было собрано у населения района свыше 35 тонн сельскохозяйственной продукции: картошки, лука, моркови, свеклы… Из них 30 тонн отправили в Казань в духовные учебные заведения, а 5 тонн — в дом престарелых Черемшанского района.

***

Успешная деятельность Черемшанского мухтасиба вряд ли была бы возможной, если бы у него не сложились прекрасные взаимоотношения с администрацией района. Помощь администрации заключается не только в том, чтобы отвести землю при строительстве мечети в том или ином селе, как нередко это происходит, но и во многом другом.

Например, ежемесячное собрание имамов проходит в конференц-зале администрации района, на котором обязательно присутствует и глава района. Для главы администрации такие встречи тоже необходимы, так как муллы — это не только религиозные служители, но и духовные лидеры жителей района. «Ранее я был первым секретарем района, ныне глава администрации, и могу сказать, что воинствующего атеизма в районе никогда не было, мы не поддерживали верующих, но и не мешали им. Сейчас, конечно, поддерживаем и стараемся помочь по мере наших сил. Они в свою очередь тоже помогают нам, прежде всего в воспитании населения, и особенно подрастающего поколения», — рассказывает глава администрации района Минсагит Шакиров. Конечно, такие же отношения у администрации района сложились и с другими конфессиями, но, поскольку большинство населения



www.darul-kutub.com

мусульманского вероисповедования, пример с мухтасибатом наиболее показателен.



*Фасыйх-хазрат Гафиев на встрече с учениками средней школы Черемшанского района РТ*

Летом мухтасибат для сельских имамов организует автобусные экскурсии по историческим местам республики. Муллы со своими семьями уже побывали в Булгаре, Казани, Биляре и других местах. Интересен тот факт, что автобус для этих целей выделяет администрация. Фасыйху-хазрату по работе нередко приходится бывать в Казани, в Духовном управлении мусульман, и глава администрации практически никогда не отказывает ему в транспорте.

«Фасыйх» означает «говорящий ясно, красноречивый». Если же произносить «Фэсих», как некоторые его односельчане, то его имя будет означать «широкий, просторный». То есть человек с широкой душой. Поэтому, видимо, одним из



www.darul-kutub.com

неотъемлемых качеств Фасыйха-хазрата является умение находить общий язык с людьми. Еще одно свидетельство тому: при решении организационных вопросов нередко к его авторитету обращаются не только имамы, но иногда и православные священники района. И кто знает, так ли все сложилось бы, если не молитва в бомболюке…

***Айназ МУХАМЕТЗЯНОВ, журналист***



www.darul-kutub.com

# ВСЯ ЖИЗНЬ В СЛУЖЕНИИ ЛЮДЯМ



*В этом году исполнится 70 лет со дня победы в Великой Отечественной войне. Нам удалось побеседовать с Мисбахом Гималетдиновым, с одним из тех, кто, дойдя до Берлина в 1945 г., отвоевал нашему поколению шанс на будущее.*

**— Расскажите, пожалуйста, немного о себе. Откуда вы родом?**

— Зовут меня Мисбах Гималетдинов. Родился в 1926 г. Родом я из Нурлатского района Республики Татарстан. Первый год войны я, 15-летний парень, был определен в комбайнеры и работал на уборке урожая в своем колхозе. На следующий год меня поставили механизатором, и я был занят на весенне-полевых работах, сеял хлеб. И наконец, когда мне исполнилось 17 лет, меня забрали в армию.

Нас отправили в учебную часть, находившуюся среди густых лесов вблизи п. Суслонгер Республики Марий Эл (этот



www.darul-kutub.com

учебный центр стал печально известным из-за своих ужасных бытовых условий). Там нам приходилось очень туго. На нас была полностью изношенная дырявая форма, а армейские ботинки настолько разошлись, что нам приходилось их скреплять гвоздями и проволокой. Многие не выдержали этих ужасающих условий и погибли от холода, сырости и плохого питания. Жили мы в сырых землянках, где на нас постоянно сыпалась земля. По ногами текла вода, поверх которой просто набросали ветвей, чтобы хоть как-то обезопасить себя от влаги.

Через 4 месяца подготовки нас отправили на фронт. Мы были этому несказанно рады. Зная о нашем бедственном положении, на первой же ж/д станции, где мы остановились, для нас приготовили горячую кашу (каждый из нас съел целый котелок) и новую чистую одежду. Меня определили в разведывательную роту, где я командовал отделением. Нас постоянно перебрасывали через линию фронта, в одной из вылазок отделение серьезно потрепали. После ранения, ввиду того, что я не мог уже служить в военной разведке, благодаря моей предыдущей профессии тракториста, меня перекинули в танковые войска. После короткого обучающего курса, наш экипаж определили в состав 5-й гвардейской танковой армии 3-го Белорусского фронта, в составе которой мне и пришлось дойти до Берлина.

Помню, как подойдя к реке Одер (граница Германии), мы вплавь по ледяной воде переплыли ее. Немцы в те дни усиленно сбрасывали нам свои пропагандистские листовки, но мы не обращали на них никакого внимания, а в ответ отправляли им свои.

Наконец, 13 апреля 1945 г. наша армия одной из первых подошла к Берлину. Целых три дня мы занимались подготовкой к решающему штурму, подтягивали в огромном количестве боеприпасы, снаряды. Затем по приказу Жукова, перед артподготовкой, во время которой был расстрелян практически



www.darul-kutub.com

весь наш боезапас, было решено использовать мощные зенитные прожекторы, чтобы ошеломить противника. Помню, в те дни нас совершенно ошеломил вид Берлина, в котором практически не осталось ни одного целого здания.

Мы все знали, что первыми на рейхстаг водрузили флаг не известные всем Егоров и Кантария, а наш соотечественник татарин Гази Загитов. Около 500 наших солдат полегло в те дни, пытаясь установить знамя над рейхстагом.

28 апреля 1945 г., за несколько дней до окончательного взятия города, наш танк подорвался на противотанковой мине. Меня сильно контузило, и весь наш экипаж отправили в госпиталь, где я и встретил весть о победе.

**— Когда вы смогли вернуться в родные места?**

— Домой я вернулся только через год, так как вынужден был все это время лечится в госпитале.

**— Вы не почувствовали ожесточения сопротивления немцев после того, как война перекинулась уже на их историческую территорию?**

— Да нет. Немцы они вообще очень дисциплинированный народ. Поэтому бессмысленного сопротивления с их стороны практически не было. Более того, я прекрасно помню, как мы даже делились друг с другом табаком. Они ведь прекрасно понимали, что мы не пришли их завоёвывать.

**— Чем вы занимались после войны? Где работали?**

— После войны вплоть до выхода на пенсию я проработал директором школы. Затем, переехав в г. Набережные Челны, я активно занялся открытием медресе, выпросил у городских властей выделения помещения в городе. В 1990-х годах также активно занимался пчеловодством и в тайне от родных откладывал вырученные от продажи меда деньги (переводя их в иностранную валюту) в свой старый военный китель. И на эти деньги в 2003 г. мне удалось построить мечеть Кул-Шариф в г. Набережные Челны.



www.darul-kutub.com



*Эта мечеть является миниатюрной копи-ей, знаменитой мечети Кул-Шариф*

***

Во время интервью Мисбах абзый очень сильно волновался. Чувствовалась, как трудно ему вновь переживать те драматические и судьбоносные для всей нашей страны дни. Но эта выдержка помогла ему не только дойти до Берлина, но и построить за свой счет мечеть, которая еще долго будет живым свидетельством необычайной судьбы нашего героя.

Через год нашему ветерану, дай Аллах ему здоровья, исполнится 90 лет. Пожелаем ему также бодро, как и сегодня, встретить большой юбилей.

***Ильнар ГАРИФУЛЛИН, журналист***



www.darul-kutub.com

# СИГЕЗ БИЗӘКЛЕ СӨЛГЕ

Борынгы Мамадыш шәһәренең төбәк тарихын чагылдыручы искиткеч бай музеенда булган кешеләр еш кына, бик озаклап, бер экспонат — бизәкләп чигелгән Сөлге янында тукталып, тирән уйларга чумып басып торалар. Чөнки ул — гадәти Сөлге түгел, ә Туган җиребезгә сигез каһарманны бүләк иткән изге Ананың өмет белән тулы күз нурларын, дәртле вә сагышлы илаһи җырларын, йөрәк җылысын, кайнар күз яшьләрен үзенә сеңдергән, эшчән вә хисчән халкыбызның йөз аклыгын, намусын, күңел байлыгын чагылдырган биниһая кадерле Сөлге. Легендар Фатыйха түти Әхмәдиева Сөлгесе. Сигез бизәкле Сөлге. Сигез бизәк — яшәргә дип бу җиһанга килеп тә, яу кырында гомерләре вакытсыз өзелгән сигез улы төсе...

Заманында миңа бу гаиләнең үтә гыйбрәтле язмышы һәм Фатыйха түтинең оныклары белән танышырга Мамадыш районындагы Урта Кирмән авылында яшәүче Габденур абзый Ибраһимов ярдәм иткән иде. Эзләнүләр барышында мин Фәттаховлар язмышына охшаган тагын берничә гаилә таптым. Биредә, Фәттаховлар турында тәфсилләп сөйли башлаганчы, укучыларыбызны кыскача гына шул гаиләләрнең берничәсе белән таныштырып үтәм.

## 1. ЛЫСЕНКОЛАР

Мәскәүдә, илебез Коралллы Көчләре Үзәк музеенда йөргәндә, 17 нче залда очраттым мин аларны. Очраттым һәм... фоторәсемнәреннән күзләремне һич кенә дә ала алмадым. Кеше ышанмаслык гаҗәеп факт: бер гаиләдән, бер ата белән ананың ун улы Бөек Ватан сугышына китеп, унысы да Җиңү яулап, исән-сау кайтканнар, батырлар булып кайтканнар! Черкасс өлкәсенең Корсунь-Шевченко районындагы Бровахи авылында туып үскән Феодосий, Петр, Степан, Михаил,



www.darul-kutub.com

Андрей, Николай, Александр, Иван, Павел, Василий Лесенколар алар! Әлеге ир-егетләр тыныч тормышта да үзләрен фидакарь җаннар итеп танытканнар. Араларында кемнәр генә юк аларның! Игенчеләр, терлекчеләр, төзүчеләр... Барысы да туып үскән җирләрендә ныклап төпләнеп калып, гаилә корып, балалар үстереп, күптармаклы меңьяшәр горур имән кебек, Лысенколар данын киләчәк гасырларга да илтә алар. Күмәк фоторәсемдә Җиңү көнендә авыл мәйданында төшкән бертуган Лысенколарның йөзләреннән, үз-үзләрен тотышларыннан эчке бер горурлык, таза рух, җирнең, тормышның чын хуҗалары булу хисе бөркелеп тора — шуңа күрә аларга кат-кат карап сокланасың...

## 2. СТЕПАНОВЛАР

Сүз дә юк, Лысенколар — искиткеч бәхетле язмыш кешеләре! Ә менә Степановлар гаиләсенә бетмәс-төкәнмәс авыр кайгылар килгән. Уйлап карагыз: Краснодар краеның Тимашевский районындагы Шкуропадский (Беренче Май) хуторында гомер итүче Епистиния Федоровна белән Михаил Николаевичның барлык уллары — тугызы да! — бик яшьләй һәлак була. Гражданнар сугышы елларында беренче уллары Александрны — 18 яшьлек якты күңелле, җырчы егетне — кызылармеецларның пушкаларын төзәтүдә булышканы өчен, 1918 елда акгвардиячеләр җәзалап-атып үтерәләр. Икенче уллары — 27 яшьлек Федор — 1939 елда япон самурайларына каршы Халхин-Гол елгасы буенда соңгы тамчы каны тамганчыга кадәр үз-үзен аямыйча сугыша. 1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышы фронтларында Федор, Павел, Василий, хәрби антларына ахыргача тугры калып, ил азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен, бер-бер артлы газиз гомерләрен бирәләр (бу вакытта аларның иң өлкәненә әле 35 яшь тә тулып өлгермәгән була). Иван белән Филиппка үз җилкәләрендә фашист әсирлеге газапларын тотарга да, партизанлык итәргә дә туры килә. Төп-



www.darul-kutub.com

чек уллары Александр исә (өлкән Степановлар тугызынчы балаларына да беренче малайларының исемен кушалар. — *Ш. М.*), 1943 елның 2 октябрендә дошманнарның контратакасын кире какканда, соңгы гранатасы белән үз-үзен һәм бер төркем фашистларны шартлатып, Днепр елгасы буенда һәлак була. Әлеге гаярь рус егетенә СССР Югары Советы Президиумының 1943 ел 25 октябрь Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән исем бирелә.

Яу кырыннан туып үскән нигезенә бары тик Николай гына әйләнеп кайта. Әмма аңа да озак яшәргә язмаган икән — сугыш җәрәхәтләреннән савыга алмыйча, бераздан ул да дөнья куя...

Музейда Епистиния Федоровнаның, аның рядовой һәм офицер улларының фоторәсемнәре янында шактый вакытлар уйланып басып тордым мин. Хәтеремдә тагын үзем ишеткән-белгән шундый ишле бер гаилә язмышын яңарттым.

## 3. АЛЕКСЕЕВЛАР

Алар турында миңа иң элек күренекле чуваш язучысы Михаил Юхма сөйләгән иде... Чувашстан Республикасының Моргауш районындагы Изедеркино авылында туып үскән сигез бертуган Алексеевлар турында китап язуы турында да әйткән иде ул шул чакта. Соңыннан Михаил Николаевич миңа, биргән вәгъдәсендә торып, «Бертуган Алексеевлар урамы» дигән китабын, култамга салып, бүләк итеп җибәрде. Мәскәүдә «Советская Россия» нәшриятында «Язучы һәм тормыш» сериясендә чыккан иде ул...

Бик яратып, дулкынланып, бер тында укып чыктым мин әлеге китапны. Шуңадырмы бертуган Алексеевларның һәркайсының исеме хәтеремә тирән уелып калды.

Гади бер чуваш крестьяны гаиләсендә Татьяна Николаевна белән Алексей Илларионович сигез егет — сигез бөркет тәрбияләп үстерәләр. Дәһшәтле кырык беренче елда ил өстенә



www.darul-kutub.com

кара афәт булып фашист козгыннары ябырылгач, аларның сигезе дә Ватан-Ана язмышы хәл ителгән алгы сызыкка бер-бер артлы китеп бара.

Күп тә үтми, Алексеевлар йорты тәрәзәсен кара кайгы шакып уза — Иван исемле уллары фашистлар белән тигезсез көрәштә батырларча һәлак була... Днепрны кичкәндә, зур каһарманлык үрнәге күрсәтеп, Григорий исемле икенче уллары үлемсезлеккә атлый. Аңа СССР Югары Советы Президиумының 1943 ел 30 октябрь Указы нигезендә Советлар Союзы Герое дигән олы исем бирелә... 1943 елда Егор исемле уллары Житомир янында, легендар Александр Матросов үрнәгендә зур фидакарьлек күрсәтеп, күкрәге белән дошманның ут өермәсен томалый, сугышчан иптәшләренә җиңүгә юл ача... 1944 елда исә яу кырында, мөһим бер биеклекне яулаганда, фашист ядрәсе Павелның гомерен кисә...

Бик авыр кичерәләр мондый олы кайгы-хәсрәтне өлкән Алексеевлар. Беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан Алексей Илларионовичны да аямый үлем. Карт солдатның йөрәге кинәт ябырылган авырлыкларны күтәрә алмый...

«Инде нишләргә, ничек гомер итәргә?» — дип торганда, Татьяна Николаевна янына фронттан бер-бер артлы уллары Фрол белән Родион кайтып төшә. Гәрчә авыр яралы булсалар да, аларны тере килеш күреп, чиксез сөенә Ана кеше. Әмма куанычы озакка бармый аның — ике фронтовик улы да сугыш җәрәхәтләреннән яшьләй үлеп китә...

Бүгенге көндә бертуган Алексеевларның тик икесе — Александр белән Михаил гына исән. Сугышның башыннан алып ахырынача кадәр үткән, күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнгән бу ветераннар хәзер Чабаксар шәһәрендә яшиләр...

Шулай да Татьяна Николаевна чагыштырмача бәхетле кеше икән: ул, сугыштан соң исән кайткан уллары кадер-тәрбиясендә тагын 25 ел яшәп, 91 яшендә вафат була...



www.darul-kutub.com

## 4. ФӘТТАХОВЛАР

Ә менә Татарстан Республикасының Мамадыш районындагы Урта Кирмән авылында гомер кичергән Фатыйха түти белән Фәттах ага Әхмәдиевларга һәм аларның сигез улларына мондый бәхет әз генә дә елмаймый. Гаҗәеп тирән драматизм белән сугарылган моңлы бу кыйссаны һич кенә дә тыныч сөйләп булмый...

...Дөрес, баштарак аларның да тормышлары түгәрәк, күңел күкләре аяз һәм кояшлы булган. Сабан тургайлы булган... Авылның иң булдыклы игенчесе, төзүчесе саналган Фәттах агай белән киндер тукымалар сугу остасы Фатыйха түтиләрнең ишле гаиләсе тирә-юньдә дан тоткан. Берсеннән-берсе уңган уллары белән бергәләп, гаилә башлыгы нарат бүрәнәләрдән күп тәрәзәле, алты почмаклы мәһабәт йорт та, каралты-куралар да торгызып куйган. Имана җирләре мулдан булгач, таза хәлле крестьяннар рәтендә йөргән алар. Хезмәтчеләр тотмаганнар — һәр эшне үзләре күмәкләшеп башкарганнар. Күмәк тормышның матурлыгын белгәнгә, файдасын күргәнгә, чын күңелдән ышанып, колхозга да иң беренчеләрдән керәләр Фатыйханыкылар. Керәләр һәм бар күңелләрен-осталыкларын биреп эшли дә башлыйлар. Гомумән, һәр яңа башлангычны күтәреп алучылар һәм аны тормышка ашыруда янып-ялкынланып эшләүчеләр, башкаларны киләчәк тормышның тагын да матуррак булачагына инандыручылар, рухландыручылар бертуган Фәттаховлар була да инде. Шәхси үрнәк, үтемле сүз, рухландыргыч җыр — менә аларның төп таяныр көчләре! Тора-бара Фәттах агайны, гаделлеге, булдыклылыгы, тынгысызлыгы өчен, яңа оешкан «Алга» колхозының баш тегермәнчесе итеп билгеләп куялар. Сынатмый ил агасы. Балалары да әти-әниләренең йөзләренә кызыллык китермиләр. Тырыш игенчеләр буларак таныталар алар үзләрен. Шуңа күрә көзен хезмәт көннәренә олавы-олавы белән иң күп ашлыкны да шушы ишле гаиләдәгеләр ала...



www.darul-kutub.com

Фатыйха түти белән Фәттах агайның иң олы уллары Исмәгыйль белән Ибраһим яшь Советлар властен саклап калу өчен, гражданнар сугышы фронтларында эчке һәм тышкы дошман белән бугазга-бугаз киләләр. Әлеге дәһшәтле көрәштә Исмәгыйль һәлак була. Ибраһим исә, кайнар канын түгә-түгә, абыйсының тәмамланмый калган эшләрен дәвам итеп, сугышны төгәлләп, туып үскән җирендә яңа тормыш төзергә ашкынып кайта. Бертуганнары Мөгътәсим, Мөхлисулла, Мәгъсүмҗан, Габделбарый, Мисбахетдин, Әгъмәлетдин белән бергәләп, Фәттаховлар данын Байрак кебек горур йөртә ул.

Авылда комсомол ячейкасы төзелгәч, аңа беренчеләрдән булып язылучылар-керүчеләр дә алар — Фәттахныкылар була. Уенын-чынын бергә кушып, «Фәттаховлар ячейкасы» дип тә йөртәләр бу беренче комсомолецларны. Урта Кирмән авыл советы башкарма комитетында сәркатиб булып эшләүче Мисбахетдин бер үк вакытта комсомол ячейкасы җитәкчесе вазифасын да җиренә җиткереп башкара. Соңрак ул, «Комсомол-яшьләр, самолётларга!» дигән чакыруга теләктәшлек белдереп, очучылыкка укырга китә һәм киләчәктә бар тормышын авиациягә бәйли…

Бөек Ватан сугышы башланганчы, гаиләдә 8 баланың икесе — Ибраһим белән Мөгътәсим генә гаилә корып өлгерә. Ибраһим авылда игенчелек белән шөгыльләнүен дәвам итә, ә Мөгътәсим башта Пермьдә, аннары Дон буендагы Ростов шәһәрендә шахтер булып эшли, үзен стахановчы буларак таныта. Хатыны Гамилә үлгәч, Исмәгыйль исемле улын, Нәсимә, Мәрьямбикә, Рәхимә исемле кызларын ияртеп, яңадан туган җиренә — Мамадышка әйләнеп кайта…

Сугыш уты кабынгач, бертуган Фәттаховлар бердәм рәвештә, үзләре теләп, яу кырына китәләр. Кайберләрен, бронь биреп, район хәрби комиссариатыннан кире борып та кайтаралар башта. Әмма алар үз сүзләрендә нык тора. Мө-



www.darul-kutub.com

гътәсим абыйны, мәсәлән, өч мәртәбә боралар. Ә дүртенче баруында ул барыбер үз теләгенә ирешә...

Бертуган Фәттаховлар төрле фронтларда, төрле гаскәрләр составында дошманга каршы аяусыз көрәштә барысы да батырларча һәлак була. Мисбахетдин исемле очучы туганнары легендар капитан Гастелло үрнәгендә олы фидакарьлек күрсәтә: хәрби заданиене үтәп кайтканда, дошман снаряды тиеп самолётына ут капкач, хәрби очкычын фашистларның җанлы көчләре, техникасы өстенә юнәлтә...

Фәттах агай, бер-бер артлы килгән кара хәбәрләрне күтәрә алмыйча, вакытсыз дөнья куя. Ә Фатыйха түти, зур сабырлык белән, ниндидер бер могҗиза туып, улларының кайсы да булса исән-сау кайтыр дип көтә — күңел түрендәге өмет утын һаман да сүндерми. Әнә бит, төпчек улы Әгъмәлетдин дә: «Кадерле Әти-Әниемә — сагынганда карар өчен!» — дип җибәргән, кулына чәчәк бәйләме тотып төшкән фоторәсеменең артына:

...Иделләрне йөзәмен дә буйлыймын,
Киткән кошлар да бер кайта,
Кайтырмын дип уйлыймын! — дип, шигъри сүзләр язган — үтә газиз-кадерле кешеләрен юатырга, рухландырырга тырышкан.

— ...Әбиебезнең иң соңгы ышанычы Әгъмәлетдин абый иде, — дип сөйли Фатыйха т үтинең оныгы, Ибраһим абыйның кызы Марзия апа Бикмурзина. — Чөнки Җиңү көненнән соң да аннан хатлар килеп торды әле. Ерак Көнчыгышта хезмәт итә иде ул. 1945 елның сентябрь аенда аның белән элемтә өзелде...

Әгъмәлетдин абыйның японнарга каршы сугышканда батырларча һәлак булу хәбәрен очраклы рәвештә генә ишеткән идем. Шулай беркөнне, безнең Урта Кирмән авылында яшәүче Миңсылу түтигә ияреп, күршедәге Чытыр (Су-Елга) авылына — аның яңа гына сугыштан кайткан энесе Мәгъсүмҗан абый Юнысовларга мендек. Менә шул фронтовик



www.darul-kutub.com

үзара сөйләшеп утырганда, безнең Әгъмәлетдин абыйның да исемен зурлап телгә алды: «Якын дуслар идек... Японнар кулындагы мөһим бер биеклекне алганда, аларның ут чәчүче пулеметы авызына күкрәге белән ятып, аны томалап, безнең сугышчыларга җиңүгә юл ачты. Соңыннан, плащ-палаткасына төреп, салютлар биреп, олылап җирләдек үзен...»

Мин моны ишеткәч тә, йөгерепләр диярлек, әбиебез янына кайттым һәм күргән-белгәннәремне чәчми-түкми аңа сөйләп бирдем. Гаҗәеп сабыр булган әбиемнең күзләреннән мөлдерәп берничә бөртек яшь тамды. Соңгы яшьләре...

Икенче көнне әбием, Мәгъсүмҗан абый янына менәр өчен, иртән-иртүк яхшылап әзерләнә башлады. Саклап тоткан әйберләрен барлап, тәмле ризыклар пешерде, улларына дип атап җыйган чикләвекләрен янчыкка тутырды. Һәм бөрчекле ак күлмәген киеп, ак шәльяулыгын ябып, мине дә үзенә ияртеп, җәһәт-җәһәт атлап, Чатырга юл тотты.

— ...Улым, син миңа Әгъмәлетдинем кебек, шуңа күрә һәммәсен яшермичә сөйлә, мин инде карт кеше — барысын да күтәрәм, — диде әбием Мәгъсүмҗан абыйга...

Фронтовик дусты ялындырмады...

Ана төпчек улының соңгы батырлыгы шаһиты булган шул якташ солдат сөйләгәннәрне, бар дөньясын онытып, сәгатьләр буе тыңлап утырды. Күңелен борчыган күп кенә сорауларга тулы җаваплар алса да, тиз генә Мәгъсүмҗан абый яныннан китәсе килмәде аның... Авылыбызга без бары тик кичкырын гына кайттык. Әбиебез, үзенең аерылмас юлдашы булган өрәңге таягына таянып, бик әкрен генә, үзалдына уйланып һәм, вакыт-вакыт газиз улларының исемнәрен берәм-берәм телгә ала-ала: «Кайларда ятасыз сез хәзер, балакайларым?» — дип өзгәләнеп кайтты.

Сабыр савытлары тәмам тулып ташкан иде әбекәебезнең... Шуннан соң урын өстенә егылды ул.



www.darul-kutub.com

